**Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы**

БОЕРЫК

Казан ш. № 21-72-53

**Төбәк лотереяларын үткәрүгә, шул исәптән лотереялар үткәрүдән кергән керемнәрдән максатчан файдалануга Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан төбәк дәүләт күзәтчелеген хәл итү буенча дәүләт вазыйфасын үтәүнең административ регламентын раслау турында**

“Лотереялар турында” 11.11.2003 ел, №138-ФЗ һәм “Татарстан Республикасы территориясендә төбәк лотереяларын оештыру һәм үткәрү өлкәсендә килеп чыга торган мөнәсәбәтләрне җайга салу турында” 06.11.2012 ел, №967 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын тормышка ашыру максатыннан чыгып, боерык бирәм:

1.Төбәк лотереяларын үткәрүгә, шул исәптән лотереялар үткәрүдән кергән керемнәрдән максатчан файдалануга Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан төбәк дәүләт күзәтчелеген хәл итү буенча дәүләт вазыйфасын үтәүнең административ регламентын (кушымта итеп бирелә) расларга.

2.Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казанчылык департаментына бу боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында теркәтергә.

3.Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы финанс министрының беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казанчылык департаменты директоры М.Д.Фәйзрахмановка йөкләргә.

**Министр** **Р.Р.Гайзатуллин**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының ___ боерыгы белән расланды

**Төбәк лотереяларын үткәрүгә, шул исәптән лотереялар үткәрүдән кергән керемнәрдән максатчан файдалануга Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан төбәк дәүләт күзәтчелеген хәл итү буенча дәүләт вазыйфасын үтәүнең административ регламенты**

## I.Гомуми нигезләмәләр

1.1.Бу Административ регламент (алга таба – Регламент) төбәк лотереяларын үткәрүгә, шул исәптән лотереялар үткәрүдән кергән керемнәрдән максатчан файдалануга Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан төбәк дәүләт күзәтчелеген (алга таба – төбәк дәүләт күзәтчелеге) хәл итүдә административ процедураларның һәм административ гамәлләрнең срокларын һәм эзлеклелеген билгели.

Дәүләт вазыйфасы атамасы: төбәк лотереяларын үткәрүгә, шул исәптән лотереялар үткәрүдән кергән керемнәрдән максатчан файдалануга төбәк дәүләт күзәтчелеген хәл итү (алга таба – дәүләт вазыйфасы).

1.2.Дәүләт вазыйфасы Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан башкарыла. Министрлыкның дәүләт вазыйфасын үтәүгә җаваплы структур подразделениесе – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казанчылык департаменты (алга таба – Департамент).

Дәүләт вазыйфасын турыдан-туры үтәүчеләр булып Департаментның оператив контрольлек һәм төбәк контрольлеге бүлеге (алга таба – Бүлек, Бүлекләр) тора.

Дәүләт вазыйфасын үтәү Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе прокуратурасы, судлар органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, экспертлар һәм эксперт оешмалары, лотереяларны оештыручылар (операторлар) – юридик затлар, үзләренең мөрәҗәгатьләре буенча, гражданнар белән берлектә хәл ителә.

Дәүләт вазыйфасы Татарстан Республикасы финанс министры (Татарстан Республикасы финанс министрының беренче урынбасары) (алга таба – министр, министрның беренче урынбасары) боерыгы нигезендә тикшерү үткәрүгә вәкаләт бирелгән Министрлыкның вазыйфаи затлары (алга таба – вазыйфаи затлар) тарафыннан башкарыла.

1.3.Дәүләт вазыйфасын үтәү түбәндәге законнар һәм норматив – хокукый актлар нигезендә җайга салына:

– “Лотереялар турында” 11.11.2003, № 138-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2003, № 46, ст. 4434; 2005, № 30, ст. 3104; 2006, № 6, ст. 636; 2008, №30, ст. 3616; 2010, № 27, ст. 3414; № 31, ст. 4183; 2011, № 27, ст. 3880; № 30 (ч.1), ст. 4590; 2013, № 19, ст.2326) (алга таба – “Лотереялар турында” Федераль закон );

– “Дәүләт контрольлеген (күзәтчелек) һәм муниципаль контрольлекне хәл иткәндә юридик затларның һәм хосусый эшмәкәрләрнең хокукларын саклау турында” 26.12.2008 № 294-ФЗ Федераль закон (Россия

Федерациясе законнар җыентыгы, 2008, № 52, ст. 6249; 2009, № 18, ст. 2140; № 29, ст. 3601; №48, ст.5711; № 52, ст. 6441; 2010, № 17, ст. 1988; № 18, ст. 2142; № 31, ст. 4160, ст. 4193, ст.4196; № 32, ст. 4298; 2011, № 1, ст. 20; № 7, ст. 905; № 17, ст. 2310; № 23, ст. 3263; №27, ст. 3880; № 30, ст. 4590; № 48, ст. 6728; 2012, № 19, ст. 2281; № 26, ст. 3446; № 31, ст.4320, 4322; № 47, ст.6402; 2013, № 9, ст.874; № 27, ст. 3477) (алга таба – № 294-ФЗ Федераль закон);

– "Реклама турында" 13.03.2006, № 38-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2006, № 12, ст. 1232; № 52 (ч. I), ст. 5497; 2007, № 7, ст. 839; № 16, ст. 1828; № 30, ст. 3807; № 49, ст. 6071; 2008, № 20, ст. 2255; № 44, ст. 4985; 2009, № 19, ст. 2279; № 39, ст. 4542; № 51, ст. 6157; № 52 (ч. I), ст. 6430; 2010, № 21, ст. 2525; № 31, ст. 4163; № 40, ст. 4969; 2011, № 15, ст. 2029; № 23, ст.3255; № 27, ст. 3880; № 29, ст. 4293; № 30 (ч. I), ст. 4566, ст. 4590, ст. 4600; № 48, ст. 6728; 2012, № 30, ст.4170; № 31, ст.4322; 2013, № 19, ст.2325; № 23, ст. 2866; № 27 ст. 3477; № 30 (ч.1) ст.4084) (алга таба – "Реклама турында" Федераль закон);

– Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2002, № 1, ст. 1; № 18, ст. 1721; № 30, ст. 3029; № 44, ст. 4295, ст. 4298; 2003, № 1, ст. 2; № 27, ст. 2700, ст. 2708, ст. 2717; № 46, ст. 4434, ст. 4440; № 50, ст. 4847, ст. 4855; № 52, ст. 5037; 2004, № 19, ст. 1838; № 30, ст. 3095; № 31, ст. 3229; № 34, ст. 3529, ст. 3533; № 44, ст. 4266; 2005, № 1, ст. 9, ст. 13, ст. 37, ст. 40, ст. 45; № 10, ст. 762, ст. 763; № 13, ст. 1075, ст. 1077, ст. 1079; № 17, ст. 1484; № 19, ст. 1752; № 25, ст. 2431; № 27, ст. 2719, ст. 2721; № 30, ст. 3104, ст. 3124, ст. 3131; № 40, ст. 3986; № 50, ст. 5247; № 52, ст. 5574, ст. 5596; 2006, № 1, ст. 4, ст. 10; № 2, ст. 172, ст. 175; № 6, ст. 636; № 10, ст. 1067; № 12, ст. 1234; № 17, ст. 1776; № 18, ст. 1907; № 19, ст. 2066; № 23, ст. 2380, ст. 2385; № 28, ст. 2975; № 30, ст. 3287; № 31, ст. 3420, ст. 3432, ст. 3433, ст. 3438, ст. 3452; № 43, ст. 4412; № 45, ст. 4633, ст. 4634, ст. 4641; № 50, ст. 5279, ст. 5281; № 52, ст. 5498; 2007, № 1, ст. 21, ст. 25, ст. 29, ст. 33; № 7, ст. 840; № 15, ст. 1743; № 16, ст. 1824, ст. 1825; № 17, ст. 1930; № 20, ст. 2367; № 21, ст. 2456; № 26, ст. 3089; № 30, ст. 3755; № 31, ст. 4001, ст. 4007, ст. 4008, ст. 4009, ст. 4015; № 41, ст. 4845; № 43, ст. 5084; № 46, ст. 5553; № 49, ст. 6034, ст. 6065; № 50, ст. 6246; 2008, № 10, ст. 896; № 18, ст. 1941; № 20, ст. 2251, ст. 2259; № 29, ст. 3418; № 30, ст. 3582, ст. 3601, ст. 3604; № 45, ст. 5143; № 49, ст. 5738, ст. 5745, ст. 5748; № 52, ст. 6227, ст. 6235, ст. 6236, ст. 6248; 2009, № 1, ст. 17; № 7, ст. 771, ст. 777; № 19, ст. 2276; № 23, ст. 2759, ст. 2767, ст. 2776; № 26, ст. 3120, ст. 3122, ст. 3131, ст. 3132; № 29, ст. 3597, ст. 3599, ст. 3635, ст. 3642; № 30, ст. 3735, ст. 3739; № 45, ст. 5265, ст. 5267; № 48, ст. 5711, ст. 5724, ст. 5755; № 52, ст. 6406, ст. 6412; 2010, № 1, ст. 1; № 11, ст. 1169, ст. 1176; № 15, ст. 1743, ст. 1751; № 18, ст. 2145; № 19, ст. 2291; № 21, ст. 2524, ст. 2525, ст. 2526, ст. 2530; № 23, ст. 2790; № 25, ст. 3070; № 27, ст. 3416, ст. 3429; № 28, ст. 3553, № 29, ст. 3983; № 30, ст. 4000, ст. 4002, ст. 4005, ст. 4006, ст. 4007; № 31, ст. 4155, ст. 4158, ст. 4164, ст. 4191, ст. 4192, ст. 4193, ст. 4195, ст. 4198, ст. 4206, ст. 4207, ст. 4208; № 41, ст. 5192, ст. 5193; № 46, ст. 5918; № 49, ст. 6409; № 50, ст. 6605; № 52, ст. 6984, ст. 6995, ст. 6996; 2011, № 1, ст. 23, ст. 29, ст. 33, ст. 54; № 7, ст. 901, ст. 905; № 15, ст. 2039, ст. 2041; № 17, ст. 2312; № 19, ст. 2714, ст. 2715, ст. 2769; № 23, ст. 3260, ст. 3267; № 27, ст. 3873; № 29, ст.

4289, ст. 4290, ст. 4291, ст. 4284; № 30, ст. 4573, ст. 4574, ст. 4584, ст. 4590, ст. 4591, ст. 4598, ст. 4601; № 45, ст. 6325, ст. 6326, ст. 6334; № 46, ст. 6406; № 47, ст. 6601, ст. 6602; № 48, ст. 6730; № 49, ст. 7025, ст. 7042, ст. 7056, ст. 7061; № 50, ст. 7342, ст. 7345, ст. 7346, ст. 7351, ст. 7352, ст. 7355, ст. 7362, ст. 7366; 2012, № 6, ст. 621; № 10, ст. 1166; № 15, ст. 1723, ст. 1724; № 18, ст. 2126, ст. 2128; № 19, ст. 2278; № 24, ст. 3068, ст. 3069, ст. 3082; № 29, ст. 3996; №31, ст.4320, ст.4322, ст.4330; №41, ст.5523; №47, ст.6402-6405; №49, ст.6752, 6757; № 53 (ч.1), ст.7577, 7580, 7602, 7639, 7640, 7641, 7643; 2013, № 4, ст. 304; №8, ст.717, 718, 719, 720; №14, ст.641, 1642, 1651, 1657, 1658, 1666; № 17, ст. 2029; №19, ст. 2307, 2318, 2323, 2325; №23, ст. 2875; № 26, ст. 3207, 3208, 3209; №27, ст. 3442, 3454, 3458, 3465, 3469, 3477, 3478; № 30 (ч.1), ст.4026, 4027, 4029, 4030, 4032, 4034, 4035, 4040 ,4044, 4078, 4081, 4082; № 31, ст.4191) (алга таба – РФ КоАП);

–“Лотереялар турында” хисап тапшыру формаларын һәм срокларын раслау турында 26.04.20012 ел, №53 н Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыгы (Россия Федерациясе Юстиция министрлыгында 2012 елның 18 июлендә теркәлгән, теркәү № 24609; (“Российская газета” 2012, №141) (алга таба – №53 н РФ Финанс министрлыгы боерыгы);

–“Оешмаларның бухгалтерия хисабы формалары турында” 02.07.2010 ел, №66н Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыгы (Россия Юстиция министрлыгында 2010 елның 2 августында теркәлгән, теркәү № 18023; Федераль башкарма хакимият органнарының норматив актлары бюллетене, № 35, 30.08.2010) (алга таба – № 66н РФ Финанс министрлыгы боерыгы);

– “Дәүләт контрольлеген (күзәтчелелек) һәм муниципаль контрольлекне хәл иткәндә юридик затларның һәм хосусый эшмәкәрләрнең хокукларын саклау турында” Федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру хакында” 30.04.2009, № 141 Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы боерыгы (Россия Юстиция министрлыгында 2009 елның 13 маенда теркәлгән, теркәлү № 13915; “Российская газета”, 2009, № 85; 2010, №156; 2011, №260) (алга таба – РФ Икътисадый үсеш министрлыгы боерыгы, № 141);

– “Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы мәсьәләләре” 06.07.2005, № 323 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы) 24.05.2006, № 20, ст.0496; 27.09.2006, № 36, ст.0978; 06.12.2006, № 46, ст.1222; 31.10.2007, № 40, ст.1583; 12.03.2008, № 10, ст.0367; 25.06.2008, № 24, ст.0929; 11.03.2009, № 9-10, ст.0343; 12.05.2010, № 18, ст.0693; 01.12.2010, № 45, ст.2040; 02.02.2011, № 5, ст.0204; 16.02.2011, № 7, ст.0292; 24.08.2011, № 32, ст.1497; 20.12.2011, № 48, ст.2580, ст.2585; 19.10.2002, № 78, ст.2607; 13.11.2012, № 83, ст.2777; 27.11.2012, № 87, ст.2890; 15.02.2013, №13, ст.0452; 29.03.2013, №24, ст.0787);

– “Татарстан Республикасы территориясендә төбәк лотереялары оештыру һәм үткәрү өлкәсендә килеп чыга торган мөнәсәбәтләрне җайга салу турында” 06.11.2012, № 967 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (Татарстан Республикасы территориясендә төбәк

лотереялары үткәрүгә төбәк дәүләт күзәтчелеген хәл итү тәртибе ягыннан) (алга таба – Төбәк лотереяларын үткәрүгә төбәк дәүләт күзәтчелеген хәл итү тәртибе) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы, 27.11.2012, № 87, ст. 2890).

1.4. Төбәк дәүләт күзәтчелеге предметы булып юридик зат тарафыннан лотерея үткәрү процессында "Лотереялар турында" Федераль законда һәм лотереялар оештыру һәм үткәрү өлкәсендә башка Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне (алга таба – мәҗбүри таләпләр) үтәү тора.

1.5. Тикшерү объекты булып лотереяны оештыручы тора. Лотереяны оештыручы һәм операторы арасында килешү булган очракта тикшерү объекты булып лотереяны оештыручы һәм операторы (алга таба – лотереяны оештыручы) тора.

1.6. Бу Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

лотерея – килешү нигезендә үткәрелә торган уенда бер як (лотереяны оештыручы) лотереяның приз фондын уйната, икенче як (лотереяда катнашучы), лотерея шартлары нигезендә отучы дип танылган очракта, отышка хокук ала. Лотереяны оештыручы белән лотереяда катнашучы арасында килешү ирекле нигездә төзелә һәм лотерея билетын, квитанция, башка документ бирү нигезендә яки лотерея шартларында күздә тотылган башка ысул нигезендә рәсмиләштерелә;

төбәк лотереясы – Россия Федерациясенең бер субъекты территориясендә үткәрелә торган лотерея;

тираж лотереясы – лотереяның приз фонды лотереяда барлык катнашучылар арасында лотерея билетлары таратылганнан соң бер тапкыр үткәрелә торган лотерея. Мондый лотереяны үткәрү лотерея билетлары партиясен тарату, лотереяның приз фондын уйнату һәм отышларны түләү, тапшыру яки бирүдән гыйбарәт булган аерым тиражларны үз эченә алырга мөмкин;

тиражсыз лотерея – отышлы лотерея билетлары эшләп чыгару стадиясендә, ягъни лотереяда катнашучылар арасында таратылганчы билгеләнелә торган лотерея. Тиражсыз лотерея үткәрелгәндә мондый лотереяда катнашучы лотереяда катнашуга түләү керткәннән соң һәм лотерея билетын алганнан соң ук үзенең лотерея билетының отышлымы яки юкмы икәнен билгеләргә мөмкин;

лотереяны оештыручы – Россия Федерациясе законы нигезендә булдырылган, Россия Федерациясендә урнашкан һәм лотерея үткәрүгә хокук алган юридик зат;

лотереяны оештыручы лотереяны турыдан-туры яки лотерея операторы аша, аның белән килешү (контракт) төзү юлы белән үткәрә һәм килешү (контракт) буенча үзенең йөкләмәләрен үтәүгә лотереяда катнашучылар алдында җавап бирә;

лотерея операторы – Россия Федерациясе законы нигезендә булдырылган, Россия Федерациясендә урнашкан, лотереяны оештыручы белән аның исеменнән һәм аның кушуы буенча лотерея үткәрүгә килешү (контракт) төзегән һәм тиешле техник средстволарга ия булган юридик зат.

Башка терминнар һәм билгеләмәләр (“Лотереялар турында” Федераль закон нигезендә билгеләнгән мәгънәдә кулланыла.

1.7.Министрлыкның вазыйфаи затларының төбәк дәүләт күзәтчелеген хәл итүдәге хокуклары һәм бурычлары

1.7.1.Министрның вазыйфаи затлары хокуклы:

1)юридик затлардан язмача запрослар нигезендә тикшерү үткәрү барышында кирәкле мәгълүмат һәм документлар соратып алуга;

2)хезмәт таныклыгын һәм тикшерү билгеләү турында министр (министрның беренче урынбасары) боерыгы күчермәсен күрсәтү юлы белән, бернинди каршылыкларсыз лотерея үткәрү урыннарында булуга һәм файдаланыла торган биналарга, корылмаларга, техник чараларга һәм җиһазларга тикшерү үткәрүгә, шулай ук кирәкле тикшеренүләр, сынаулар, экспертиза һәм башка контрольлек чаралары үткәрүгә;

3)юридик затларга ачыкланган мәҗбүри таләпләрне юкка чыгару турында күрсәтмәләр бирүгә;

4)мәҗбүри таләпләрне бозуга бәйле административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә һәм мондый бозуларны кисәтү буенча чаралар күрүгә;

5)вәкаләтле органнарга, җинаять билгеләре буенча җинаять эшләре кузгату турында мәсьәләләрне хәл итү өчен, мәҗбүри таләпләрне бозуларга бәйле материаллар җибәрүгә;

6)юридик затка күчмә тикшерү үткәрү өчен үзенә карата тикшерү үткәрелә торган юридик зат белән гражданлык-хокукый һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаган һәм тикшерелә торган затларның аффилирлы затлары булып тормаган экспертлар, эксперт оешмалары җәлеп итүгә.

1.7.2.Министрлыкның вазыйфаи затлары бурычлы:

1)мәҗбүри таләпләр, бозуларны кисәтү, ачыклау һәм булдырмый калу буенча Россия Федерациясе законы нигезендә бирелгән вәкаләтләрне үз вакытында һәм тулы күләмендә үтәүгә;

2)Россия Федерациясе законын, үзенә карата тикшерү үткәрелә торган юридик затның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәүгә;

3)тикшерүне тикшерү үткәрү турында министр (министрның беренче урынбасары) боерыгы нигезендә, тикшерү, тикшерүнең билгеләнеше нигезендә үткәрүгә;

4)тикшерүне фәкать хезмәт вазыйфаларын үтәү вакытында гына үткәрүгә, күчмә тикшерүне фәкать хезмәт таныклыкларын, министр (министрның беренче урынбасары) боерыгы күчермәләрен күрсәтү нигезендә һәм № 294-ФЗ Федераль законның 10 статьясындагы 5 өлешендә күздә тотылган очракта, прокуратура органы белән тикшерү үткәрүне килештерү турында документ күчермәсен күрсәтү нигезендә генә үткәрүгә;

5)юридик зат җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә тикшерү үткәрүгә комачауламауга һәм тикшерү предметына кергән мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирүгә;

6)тикшерү үткәрүне карап торган юридик зат җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә тикшерү предметына кергән мәгълүмат һәм документларны тапшыруга;

7)юридик зат җитәкчесен, башка вазыйфаи затын яки вәкаләтле вәкилен тикшерү нәтиҗәләре белән таныштыруга;

8)ачыкланган бозу фактлары буенча күрелә торган чараларны билгеләүдә әлеге чараларның бозулар авырлыгына, аларның кешеләр тормышы, сәламәтлеге, хайваннар, үсемлекләр, әйләнә-тирә мохит, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр) объектлары, дәүләт иминлеге, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу өчен ни дәрәҗәдә куркыныч белән янавыннан чыгып эш итүгә, шулай ук гражданнарның, шул исәптән хосусый эшмәкәрләрнең, юридик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен нигезсез чикләүгә юл куймауга;

9)үзләренең гамәлләренә юридик затлар Россия Федерациясе законында билгеләнгән тәртиптә шикаять белдергәндә, үзләренең гамәлләренең нигезлеген дәлилләүгә;

10)№ 294-ФЗ Федераль закон нигезендә билгеләнгән тикшерү үткәрү срокларын үтәүгә;

11)юридик заттан Россия Федерациясе законында күздә тотылмаган документлар һәм башка мәгълүматлар таләп итүгә;

12)күчмә тикшерү үткәрү башланганчы юридик затның җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле үтенече белән аларны бу Регламент нигезләмәләре белән таныштыруга;

13)үткәрелгән тикшерү турында юридик затларны тикшерүләрне учет журналына теркәп куюга.

1.8.Лотерея оештыручының тикшерү үткәрелгәндәге хокуклары һәм бурычлары

1.8.1.Лотерея оештыручы җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле хокуклы:

1)тикшерү үткәрүдә турыдан-туры катнашуга, тикшерү предметына кергән мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирүгә;

2)Министрлыктан, аның вазыйфаи затларыннан тикшерү предметына кергән һәм №294-ФЗ Федераль закон нигезендә тапшырылырга тиешле булган мәгълүмат алуга;

3)тикшерү нәтиҗәләре белән танышуга һәм тикшерү актында тикшерү нәтиҗәләре белән танышуы, алар белән, шулай ук Министрлыкның вазыйфаи затларының аерым гамәлләре белән килешүе яки килешмәве турында күрсәтүгә;

4)юридик затның хокукларын бозуга китергән Министрлыкның вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмау) Россия Федерациясе законы нигезендә административ тәртиптә һәм (яки) суд тәртибендә шикаять белдерүгә.

1.8.2.Лотереяны оештыручы җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле бурычлы:

1)тикшерү үткәрелгәндә шунда булуга яки мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча чаралар оештыру һәм үткәрүгә җаваплы вәкаләтле вәкилләрнең тикшерү үткәрелгәндә булуын тәэмин итүгә;

2)тикшерү үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан сорала торган документлар һәм материаллар, шулай ук тикшерү предметына кергән мәсьәләләр буенча телдән һәм язмача аңлатмалар тапшыруга;

3)күчмә тикшерү үткәрүче Министрлыкның вазыйфаи затларының, шулай ук күчмә тикшерүдә катнашучы экспертларның, эксперт оешмалары вәкилләренең юридик зат территориясенә, юридик зат тарафыннан

эшчәнлегендә файдаланыла торган биналарга, корылмаларга, бүлмәләргә керү, юридик зат тарафыннан файдаланыла торган техник средстволар һәм җиһазларны карау – танышу мөмкинлеген тәэмин итүгә;

4)тикшерүләрнең учет журналын алып баруга, журналда үткәрелә торган тикшерүләр, дәүләт күзәтчелеге органы атамасы, тикшерүнең башлану һәм тәгәлләнү даталары, тикшерү вакыты, хокукый нигезләре, тикшерү максатлары, бурычлары һәм предметы, ачыкланган бозулар һәм бирелгән күрсәтмәләр турында мәгълүматлар, шулай ук тикшерүне үткәрүче вазыйфаи затның яки вазыйфаи затларның фамилияләре, исемнәре, атасының исеме һәм вазыйфалары, имзасы яки имзалары булырга тиеш. Тикшерүләрнең учет журналының битләре тегелгән, номер сугылган һәм юридик зат мөһере белән расланган булырга тиеш.

1.9.Дәүләт вазыйфасын үтәү нәтиҗәләре булып тора:

1)лотереяны оештыручыны тикшерү акты (бу Регламентка № 1 кушымта, тикшерү үткәрү турында актның типовой формасы РФ Икътисадый үсеш министрлыгының 30.04.2009 ел, №141 боерыгы белән расланган);

2)бозулар ачыкланганда:

–“Лотереялар турында” Федераль законның 24 статьясындагы 2 өлешендә билгеләнгән очракларда лотерея оештыручыга бирелгән, үтәү срогын күрсәтеп, ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны юкка чыгару турында күрсәтмә (бу Регламентка № 2 кушымта);

–РФ КоАП 28.3 статьясындагы 2 өлешенең 84 пункты нигезендә төзелгән административ хокук бозу турында беркетмә (бу Регламентка № 3 кушымта);

–“Лотереялар турында” Федераль законның 24 статьясындагы 3 пунктында күздә тотылган нигезләр булганда, төбәк лотереясын үткәрүгә рөхсәтне кире алу турында (төбәк кызыксындыру лотереясының гамәлдә булуын туктату турында) судка гариза;

–суд карары законлы көченә кергәнче лотерея үткәрүгә рөхсәтнең гамәлдә булуын (кызыксындыручы лотереяның гамәлдә булуын) туктатып тору турында карар һәм лотерея оештыручыга мондый карарларны нигезләп җибәрелгән, әлеге рөхсәтне кире алу турында гаризаны судка җибәрү хакында карар (бу Регламентка № 4, № 5 кушымталар);

–үткәрелгән күчмә тикшерү турында тикшерүләрнең учет журналына теркәп кую (бу Регламентка № 6 кушымта, тикшерүләрнең учет журналының типовой формасы РФ Икътисадый үсеш министрлыгының 30.04.2009 ел, №141 боерыгы белән расланган).

Дәүләт вазыйфасын үтәүгә нигез булып Министрлыкка гражданнардан, шул исәптән хосусый эшмәкәрләрдән, юридик затлардан мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан мәгълүматлар алыну торган очракта дәүләт вазыйфасын үтәү нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчегә “Россия Федерациясендә гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү тәртибе турында” 02.05.2006 ел, №59-ФЗ Федераль закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә җавап җибәрелә.

Лотерея оештыручы тарафыннан Министрлык компетенциясенә кермәгән Россия Федерациясе законы таләпләрен бозулар ачыкланган очракта тиешле вәкаләтле органнарга, җинаять билгеләре буенча җинаять

эшләре кузгату турында мәсьәләләрне хәл итү өчен, мәҗбүри таләпләрне бозуга бәйле материаллар җибәрелә.

## 2.Дәүләт вазыйфасын үтәү тәртибенә карата таләпләр

2.1.Дәүләт вазыйфасын үтәү турында мәгълүмат бирү тәртибе

2.1.1.Департаментның урнашу урыны: Казан ш., Уң як болак ур., 5 й.

2.1.2.Төбәк дәүләт күзәтчелеген хәл итү мәсьәләләре буенча Департаментка документлар һәм мөрәҗәгатьләр җибәрү өчен почта адресы: 420111, Казан ш., Уң як болак ур., 5 й.

2.1.3.Департаментның эш графигы: дүшәмбе-пәнҗешәмбе 9.00 дән 18.00 сәгатькәчә, җомга – 9.00 дән 16.45 сәгатькәчә, төшке аш вакыты: 12.45тән 13.30 сәгатькәчә, шимбә һәм якшәмбе – ял көннәре.

Җәмәгать транспорты белән "Үзәк стадион" тукталышына кадәр барырга:

–№6, 12, 15, 29, 35, 37, 47, 74, 75, 98 автобуслар;

–№2, 4, 17 троллейбуслар белән;

–метрода "Кремль" станциясенә кадәр.

2.1.4.Департаментның оператив контрольлек бүлеге һәм төбәк контрольлеге бүлегенең белешмәләр алу өчен телефоннары: (843) 291-96-81, 291-96-82, 291-96-83.

2.1.5.Министрлыкның "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайты адресы: (http://www.minfin.tatar.ru), электрон почта адресы: uslugi.kazna@tatar.ru.

2.1.6.Кызыксынулы затларга дәүләт вазыйфасын үтәү мәсьәләләре буенча мәгълүмат, дәүләт вазыйфасын үтәүнең барышын үтәү турында мәгълүмат тапшырыла:

–телдән мөрәҗәгать буенча (шәхсән яки телефон аша);

–язмача мөрәҗәгать буенча;

–электрон почта аша;

–Министрлыкның рәсми сайтыннан, "Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы" (http://uslugi@tatar.ru) Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасыннан (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы) файдалану нигезендә электрон рәвештә хат җибәрү юлы белән;

–Департамент бинасындагы мәгълүмати стенд аша.

Телдән мөрәҗәгатькә җавап мөрәҗәгать ителгәннән соң кичекмәстән бирелә, язмача мөрәҗәгатькә һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгатькә җавап лотереяны оештыручыга почта аша яки электрон адресына әлеге мөрәҗәгать Департаментта теркәүгә алынганнан соң 30 көннән дә артмаган срокта җибәрелә.

Телефоннан шалтыратуны тыңлаган департаментның вазыйфаи заты куелган мәсьәләләргә мөстәкыйль җавап бирә алмаганда, телефоннан шалтырату башка вазыйфаи затка күчерелергә тиеш яки мөрәҗәгать иткән затка кирәкле информация алу өчен телефон номеры хәбәр ителергә тиеш.

2.1.7.Министрлыкның рәсми сайтына, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталына, Департамент бинасында мәгълүмати стендка түбәндәге мәгълүматлар урнаштырыла:

–дәүләт вазыйфасын үтәү тәртибенә кагылышлы Россия Федерациясе законының һәм Татарстан Республикасы законының төп нигезләмәләре турында;

–бу Регламент (Департамент бинасындагы мәгълүмати стендка бу Регламентның аерым өзекләре урнаштырыла);

–министр боерыгы белән расланган планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планы (алга таба – план);

–Департаментның урнашу урыны, эш графигы, телефоннары һәм факс номерлары, электрон почта адресы;

–дәүләт вазыйфасын хәл итү барышындагы гамәлләргә (гамәл кылмау) һәм карарларга шикаять белдерү тәртибе;

–дәүләт вазыйфасын үтәүдә гамәлләр эзлеклелеген чагылдырган блок-схема.

2.1.8.Халыкка телдән мәгълүмат җиткерү массакүләм мәгълүмат чараларын – радио, телевидениене җәлеп итү нигезендә хәл ителә.

Радио һәм телевидение аша мәгълүмат җиткерүгә җаваплы белгечләрнең чыгышлары министр (министрның беренче урынбасары) белән килештерелә.

2.2.Юридик затлардан төбәк дәүләт контрольлеге буенча чаралар үткәрүгә түләү алынмау

Төбәк дәүләт күзәтчелеге буенча чаралар үткәрүгә юридик затлардан түләү алынмый, шул исәптән, тикшерү үткәрүгә җәлеп ителгән экспертлар һәм эксперт оешмалары хезмәте күрсәтүгә.

2.3.Дәүләт вазыйфасын үтәү срогы

Планлы, планнан тыш, күчмә, документлар тикшерү үткәрү срогы егерме эш көненнән артмаска тиеш.

Бер кече эшмәкәрлек субъектына карата планлы күчмә тикшерүләр үткәрүнең гомуми срогы бер ел эчендә артмаска тиеш:

кече предприятие өчен – илле сәгатьтән;

микропредприятие өчен – унбиш сәгатьтән.

Катлаулы һәм (яки) озакка сузылган тикшеренүләр, сынаулар, күчмә планлы тикшерү үткәрүче Министрлыкның вазыйфаи затларының нигезле тәкъдимнәре белән махсус экспертизалар һәм тикшеренүләр үткәрү зарурилыгы белән бәйле чыгарма очракларда күчмә планлы тикшерү үткәрү срогы министр тарафыннан озайтылырга мөмкин, әмма күп дигәндә егерме эш көненә генә, ә кече предприятиеләргә, микропредприятиеләргә карата – күп дигәндә унбиш сәгатькә генә.

Россия Федерациясенең берничә субъекты территориясендә үз эшчәнлеген алып баручы юридик затка карата документлар, шулай ук күчмә тикшерү үткәрү срогы юридик затның һәр филиалы, вәкиллеге, аерымланган структур подразделениесе буенча аерым билгеләнә, шул ук вакытта тикшерү үткәрүнең гомуми срогы алтмыш эш көненнән артмаска тиеш.

2.4.Тикшерүләр үткәрүгә нигезләр

2.4.1.Планлы тикшерүләр, Татарстан Республикасы Прокуратурасы белән килештерелгәннән соң, расланылган еллык план нигезендә үткәрелә.

Планны булдыру һәм аны дәүләт контрольлеге (күзәтчелек) органының "Интернет" челтәрендәге рәсми сайтына урнаштыру тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 30.06.2010 ел, №489 карары белән расланган Дәүләт контрольлеге (күзәтчелек) органнары һәм муниципаль контрольлек органнары тарафыннан Юридик затларга һәм хосусый эшмәкәрләргә планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планнарына муниципаль контрольлек итү кагыйдәләре нигезендә билгеләнгән.

Планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планына планлы тикшерүне кертүгә нигез булып:

а) юридик затка төбәк лотереяларын үткәрүгә рөхсәт бирелгән көннән;

б) соңгы планлы тикшерү үткәрү төгәлләнгән көннән соң бер ел узу тора.

2.4.2.Планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планына кертелмәгән тикшерү планнан тыш тикшерү булып тора.

Планнан тыш тикшерү үткәрүгә нигез булып тора:

а) мәҗбүри таләпләрне бозуны юкка чыгару турында Министрлык тарафыннан бирелгән күрсәтмәнең юридик зат тарафыннан үтәлү срогы чыгуы;

б) Министрлыкка гражданнардан, шул исәптән хосусый эшмәкәрләрдән, юридик затлардан мөрәҗәгатьләр һәм гаризаларның, дәүләт хакимияте органнарыннан (дәүләт күзәтчелеге органы яки муниципаль контрольлек органы вазыйфаи затларыннан) җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан мәҗбүри таләпләрне бозу фактлары турында мәгълүмат алынуы;

в)Россия Федерациясе Президенты яки Россия Федерациясе Хөкүмәте яисә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты кушуы белән чыгарылган планнан тыш тикшерү үткәрү турында министр (министрның беренче урынбасары) боерыгы булу.

Бу пунктның "б" пунктчасында күрсәтелгән нигез буенча планнан тыш күчмә тикшерү Министрлык тарафыннан кичекмәстән, прокуратура органына №294-ФЗ Федераль законның 10 статьясындагы 12 өлешендә билгеләнгән тәртиптә хәбәр итү юлы белән, үткәрелергә мөмкин.

2.5.Төбәк дәүләт күзәтчелеген турыдан-туры хәл итүче вазыйфаи затлар

Төбәк дәүләт күзәтчелеген турыдан-туры тикшерү үткәрүне министр (министрның беренче урынбасары) боерыгы нигезендә вәкаләт бирелгән Бүлекләрнең вазыйфаи затлары хәл итә:

1)Департаментның оператив контрольлек бүлеге начальнигы һәм төбәк контрольлеге бүлеге начальнигы;

2)Департаментның оператив контрольлек бүлеге начальнигы урынбасары һәм төбәк контрольлеге бүлеге начальнигы урынбасары;

3)Департаментның оператив контрольлек бүлеге белгечләре һәм төбәк контрольлеге бүлеге белгечләре.

2.6.Юридик затларның № 294-ФЗ Федераль законны бозган өчен җаваплылыгы

№294-ФЗ Федераль законны бозуга юл куйган, тикшерүләр үткәрүгә нигезсез комачаулаган, тикшерүләрдән читләшкән һәм (яки) ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны юкка чыгару турында Министрлык

күрсәтмәсен билгеләнгән срокта үтәмәгән юридик затлар, аларның җитәкчеләре, башка вазыйфаи затлар яки юридик затларның вәкаләтле вәкилләре Россия Федерациясе законы нигезендә җавап бирә.

2.7.Тикшерү үткәрүдә Министрлык, аның вазыйфаи затлары җаваплылыгы

Министрлык, аның вазыйфаи затлары, тикшерү үткәргәндә вазыйфаларын, хезмәт бурычларын тиешенчә үтәмәгәндә, хокукка каршы гамәлләр кылганда (гамәл кылмау) Россия Федерациясе законы нигезендә җавап бирә.

Министрлык Россия Федерациясе законын һәм Татарстан Республикасы законын бозуда гаепле вазыйфаи затларга карата күрелгән чаралар турында мондый чаралар күрелгәннән соң ун көн эчендә хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре санга сугылмаган юридик затка язмача рәвештә хәбәр җиткерергә тиеш.

## 3.Юридик затларга карата куела торган мәҗбүри таләпләр

Юридик затларга карата куелып, үтәлеше контрольдә тотыла торган мәҗбүри таләпләр исемлеге, тиешле таләпләрне билгеләгән норматив-хокукый актларны күрсәтеп, 1 нче таблицада китерелә.

1 нче таблица. Тикшерү үткәргәндә юридик затларга карата куела торган мәҗбүри таләпләр исемлеге

| **Контрольдә тотыла торган объектлар** | **Мәҗбүри таләп эчтәлеге** | **Мәҗбүри таләпне билгеләүче норматив-хокукый акт** | **Тикшерү үткәргәндә юридик затлар тарафыннан күрсәтелергә тиешле документлар исемлеге** |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| I. Контрольдә тотыла торган барлык объектлар | 1. Лотерея үткәрү максатыннан чыгып, лотереяны оештыручы һәм (яки) лотерея операторы тарафыннан төзелгән килешүләрнең (контрактлар) булуы; | “Лотереялар турында” Федераль законның 2 статьясындагы 6,9 пунктлары; Төбәк лотереяларын үткәрүгә төбәк дәүләт контрольлеген хәл итү тәртибе | Лотерея үткәрү максатыннан чыгып, лотереяны оештыручы һәм (яки) лотерея операторы тарафыннан төзелгән килешүләр (контрактлар) |
| | 2. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан бирелгән лотерея үткәрүгә рөхсәтнең яки кызыксындыру лотереясы үткәрү турында уведомлениенең булуы | “Лотереялар турында” Федераль законның 6 статьясы; РФ КоАП 14.27 статьясының 1 пункты | Лотерея үткәрүгә рөхсәт яки кызыксындыру лотереясы үткәрү турында уведомление күчермәсе |
| | 3. Лотерея үткәрүгә рөхстәне рәсмиләштергәндә лотерея үткәрү шартларының игълан ителгән шартларга, шулай ук Россия Федерациясе законына туры килүе | “Лотереялар турында” Федераль законның 6,8,9 статьялары | Лотерея үткәрү шартлары (лотерея шартларына үзгәрешләр кертелгән очракта шартлар лотерея оештыручы тарафыннан Министрлык[1] белән килештерелергә тиеш) |

[1] **Лотереяны оештыручы, “Лотереялар турында” Федераль законныћ 8 статьясындагы 2 бњлегенеђ 2,5, 6, 8, 9, 10, 11, 15 цђм 16 пунктларында књздђ тотылган лотерея шартларына њзгђрешлђр кертњ љчен, лотерея њткђрњгђ яћа рљхсђт алырга тиеш.**

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 4. Кулланылыштагы лотерея җиһазының Россия Федерациясе законы нигезендә лотерея җиһазына куела торган таләпләргә туры килүе | “Лотереялар турында” Федераль законның 2,12.1 статьялары; “Лотереялар турында” Федераль законның 6 статьясындагы 6 өлешенең, 6 пункты | Лотерея җиһазының тасвирламасы һәм техник характеристикалары (файдаланыла торган программаның контроль суммаларын күрсәтеп, эксплуатация документларын һәм әлеге программада декларацияләнмәгән мөмкинлекләрнең булмавына контрольлек таләпләрен үтәүне раслаучы документны кертеп) |
| | 5. Министрлыкка лотереяны оештыручы тарафыннан тулы һәм дөрес мәгълүмат тапшыру | “Лотереялар турында” Федераль законның 4 статьясы; Төбәк лотереяларын үткәрүгә төбәк дәүләт контрольлеген хәл итү тәртибенең 5 пункты | РФ Финанс министрлыгының №53 н боерыгы белән расланган лотереялар турында хисап формалары |
| | 6. Лотереяны оештыручының ачыкланган бозуны юкка чыгару турында Министрлык карарын билгеләнгән срокта үтәве | “Лотереялар турында” Федераль законның 21 статьясындагы 9 пунктының 3 пунктчасы; Төбәк лотереяларын үткәрүгә төбәк дәүләт контрольлеген хәл итү тәртибенең 6 пункты | Министрлыкка элек тапшырылган күрсәтмә (булганда) |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 7. Лотерея үткәрүдән алынган средстволардан максатчан файдалану турында таләпләрне үтәү (лотереядан максатчан чигерүләрне “Лотереялар турында” Федераль законның 11 статьясында күздә тотылган максатларга җибәрү, шулай ук лотереяда катнашучыга отышны түләү, тапшыру яки бирү) (бу таблицаның 11 п., 17 п. кара) | “Лотереялар турында” Федераль законның 24 статьясындагы 3 пунктының 1 пунктчасы; | Лотереяда катнашучыга отышны түләүне, тапшыруны яки бирүне раслаучы документлар;<br>Бу таблицаның 11 п., 17 п. кара |
| | 8.Лотерея оештыручының “Лотереялар турында” Федераль закон таләпләрен һәм лотерея шартларын үтәве | “Лотереялар турында” Федераль законның 24 статьясындагы 3 пунктының 2 пунктчасы; | Лотереяны оештыручы раслаган лотерея шартлары |
| | 9. “Лотереялар турында” Федераль законның 10 статьясында билгеләнгән лотереяның мәҗбүри нормативларын үтәү (кызыксындыру лотереяларыннан тыш; лотереядан максатчан чигерүләр турында таләпләр дәүләт лотереяларына кагылмый)<br>(бу таблицаның 11 п., 17 п. кара) | “Лотереялар турында” Федераль законның 24 статьясындагы 3 пунктының 3 пунктчасы; | Бу таблицаның 11 п., 17 п. кара |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 10. Таратылган һәм таратылмаган лотерея билетларының учет тәртибен үтәү | “Лотереялар турында” Федераль законның 6 статьясындагы 6 өлешенең 8 пункты; Төбәк лотереяларын үткәрүгә төбәк дәүләт контрольлеген хәл итү тәртибенең 5 пунктының 7,12 абзацлары | Эшләп чыгарылган һәм сатылган лотерея билетларының (башка мәгълүмат чыганакларының) тулаем саны һәм һәр чыгарылыш санын раслаучы документлар, аларның бәясен һәм кайда сатылганлыгын күрсәтеп (кызыксындыру лотереясыннан тыш);<br>Төбәк лотереяларын үткәрү турында лотереяларны оештыручылар (операторлар) хисаплары |
| | 11.Түбәндәгеләрне үтәү:<br>–таратылмыйча калган лотерея билетларын кире кайтару, саклау, юкка чыгару яки алардан файдалану тәртибен;<br>–таратылмый калган лотерея билетларын алу тәртибен | “Лотереялар турында” Федераль законның 6 статьясындагы 6 өлешенең 9,10 пунктлары; Төбәк лотереяларын үткәрүгә төбәк дәүләт контрольлеген хәл итү тәртибенең 5 пунктының 11, 12 абзацлары | Һәр чыгарылыш буенча сатылмыйча калган һәм юкка чыгарылган билетлар турында актлар (кызыксындыру лотереяларыннан тыш);<br>Төбәк лотереяларын үткәрү турында лотереялар оештыручыларның (операторлар) хисаплары |
| | 12.Сорап алынмаган отышларны саклау тәртибен һәм отышларны алу сроклары чыккач аларны сорап алу тәртибен үтәү | “Лотереялар турында” Федераль законның 6 статьясындагы 6 өлешенең 11 пункты; Төбәк лотереяларын үткәрүгә төбәк дәүләт контрольлеген хәл итү тәртибенең 5 пунктының 5,12 абзацлары | Тулаем алганда бер ел эчендә һәм лотереяның һәр чыгарылышы буенча түләнгән отышлар күләме һәм суммасы турында, отышларны бирү өчен билгеләнгән срок чыкканнан соң, шулай ук отышларны алу өчен дәгъва бирү срогы чыкканнан соң сорап алынмый калган отышларның күләме һәм суммасы турында мәгълүматлар; төбәк лотереяларын үткәрү турында |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | лотереялар оештыручыларның (операторлар) хисаплары |
| II. Төбәк кызыксындыру лотереясын оештыручылар | 13. Лотереяның приз фонды кызыксындыру лотереясын оештыручы хисабына булдырылырга тиеш.<br>Приз фонды бурычлар белән чикләнмәгән булырга тиеш, лотереяда катнашучыларга отышларны түләү, тапшыру яки бирү бурычларыннан тыш | “Лотереялар турында” Федераль законның 17 статьясы; Төбәк лотереяларын үткәрүгә төбәк дәүләт контрольлеген хәл итү тәртибенең 5 пунктының 8 абзацы | Лотерея үткәрү максатыннан чыгып лотерея оештыручы белән лотерея операторы арасында төзелгән килешүләр (шартнамәләр), әлеге килешүләрне (шартнамәләр) күчермәләре белән (күчермә нотариуста расланмаган очракта төп нөсхәләрен күрсәтеп).<br>Бухгалтерия хисабы күчермәләре, соңгы хисап датасына һәм узган финанс елы йомгаклары буенча салым органы билгесе белән.<br>Лотереяларны оештыручыларның һәм операторларның хисаплары күчермәләре.<br>Лотерея үткәрүгә бәйле чыгымнарны раслаучы документлар. |
| | 14.Лотерея билетларының “Лотереялар турында” Федераль закон нигезендә лотерея билетларына куела торган таләпләргә туры килүе (бу таләпләр лотерея шартларында күздә тотылса)<br>Лотерея билетларында түбәндәге мәҗбүри реквизитлар булырга тиеш: | “Лотереялар турында” Федераль законның 12 статьясы; Төбәк лотереяларын үткәрүгә төбәк дәүләт контрольлеген хәл итү тәртибенең 5 | Лотерея билеты (квитанция, лотерея шартларында күздә тотылган башка документ) макеты, аңа карата мәҗбүри таләпләр тасвирламасы белән, һәм лотерея билетын ялган билеттан саклау ысуллары кирәк булганда – билеттагы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | –лотерея үткәрүгә рөхсәт номеры һәм рөхсәтне бирү датасы;<br>–лотерея үткәрүгә рөхсәт биргән Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы атамасы,<br>Төбәк лотереясының дәүләт теркәү номеры;<br>–лотерея атамасы;<br>–лотерея билеты номеры;<br>–лотереяны оештыру атамасы һәм аның элемтәгә керү өчен телефон номеры;<br>–лотереяда катнашучыны лотерея турында дөрес мәгълүмат белән җитәрлек дәрәҗәдә таныштыру өчен, отышны билгеләү алгоритмы турында, отыш күләме һәм аны алу тәртибе турында лотерея шартларыннан өземтәләр;<br>–лотереяның приз фонды күләме (лотереяны үткәрүдән кергән керемнән процентларда);<br>–лотерея билетының билгеләнгән бәясе яки бер ставканың билгеләнгән бәясе (минималь уен комбинациясе бәясе);<br>–лотереяның приз фондын уйнату датасы һәм урыны, шулай ук отышның рәсми нәтиҗәләрен бастырып чыгару сроклары һәм чыганаклары;<br>–отышларны алу урыны һәм сроклары турында мәгълүмат. | пунктының 6 абзацы. | яшерен язуларның, рәсемнәр яки билгеләрнең тасвирламасы белән. |
| | 15. Кызыксындыру лотереясын үткәрү турында реклама чаралары уздыру очрагында рекламада чараны үткәрү сроклары һәм мондый чараны оештыручы турында мәгълүмат чыганагы, аны үткәрү кагыйдәләре, мондый чара нәтиҗәләре буенча призлар яки отышлар саны, аларны алу сроклары, урыны һәм тәртибе күрсәтелергә тиеш. | “Реклама турында” Федераль законның 9 статьясы. | Реклама чараларын үткәрү очрагында реклама белдерүе. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| III. Төбәк тираж лотереясын оештыручы | 16. Төбәк тираж лотереясын оештыручылар һәр лотерея тиражының приз фондын уйнату өчен лотереяны оештыручы тарафыннан тираж комиссиясе оештырылырга тиеш. | “Лотереялар турында” Федераль законның 2 статьясы; Төбәк лотереяларын уткәругә төбәк дәүләт контрольлеген хәл итү тәртибе 5 пунктының 10 абзацы | Тираж комиссиясе составы турында мәгълүмат, тираж лотереясының приз фондын уйнату йомгаклары буенча тираж комиссиясе беркетмәсе |
| | 17. Лотереяның приз фонды лотереяны үткәрүдән кергән керем хисабына булдырыла.<br>Приз фонды тираж үткәрелгәнче булдырыла.<br>Приз фондының учет һәм аны саклау тәртибе приз фондларын аерым саклауны һәм аларның аерым учетын тәэмин итәргә тиеш. | | Лотереяны үткәрү максатыннан чыгып, лотереяны оештыручы белән лотерея операторы арасында төзелгән килешүләр (шартнамаләр), әлеге килешүләр (шартнамәләр) күчермәләре белән (күчермәләр нотариуста расланмаган очракта) төп нөсхәләрен күрсәтеп) |
| | 18. Лотереяның приз фонды күләме лотереяны үткәрүдән кергән керемгә карата кимендә 50% тәшкил итәргә тиеш. | “Лотереялар турында” Федераль законның 10 статьясы; Төбәк лотереяларын үткәругә төбәк дәүләт контрольлеген хәл итү тәртибенең 5 пунктының 8 абзацы. | Бухгалтерия хисабы күчермәсе, соңгы хисап датасына һәм узган финанс елы йомгаклары буенча салым органы билгесе белән.<br>Соңгы хисап датасына финанс (бухгалтерия) хисабының дөреслеге турында аудитор бәяләмәсенең нотариуста расланган күчермәсе. Лотерея үткәрү чыгымнарын раслаучы документлар. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 19. Лотереяны оештыручы квартал саен лотерея үткәрүдән кергән керемнең 10%ы күләмендә лотереядан максатчан чигерүләрне хәл итәргә тиеш. | “Лотереялар турында” Федераль законның 11 статьясы; Төбәк лотереяларын үткәрүгә төбәк дәүләт контрольлеген хәл итү тәртибенең 5 пунктының 4 абзацы. | Лотереяларны оештыручыларның һәм лотереялар операторларының хисаплары күчермәләре. Кредит оешмасы тарафыннан бирелгән, лотереядан максатчан чигерүләр күләмнәрен һәм аны үткәрүгә (кызыксындыру лотереясыннан тыш) бәйле чыгымнар күләмнәрен раслаучы документ. |
| | 20. Приз фонды бурычлар белән чикләнмәгән булырга тиеш, лотереяда катнашучыларга отышларны түләү, тапшыру яки бирү бурычларыннан тыш. Лотереяның приз фонды откан лотереяда катнашучыларга отышларны түләүгә, тапшыру яки бирүгә генә тотылырга тиеш. Натуралата отышлар тиешле акча эквивалентына ия булырга тиеш. | “Лотереялар турында” Федераль законның 17 статьясы; Төбәк лотереяларын үткәрүгә төбәк дәүләт контрольлеген хәл итү тәртибенең 5 пунктының 3,7 абзацлары. | Кредит оешмасы тарафыннан бирелгән, приз фонды суммасын һәм конкрет датага лотерея үткәрүдән (кызыксындыру лотереясыннан тыш) алынган средстволарның гомуми күләме. Эшләп чыгарылган һәм сатылган лотерея билетларының (башка мәгълүмат чыганаклары) тулаем саны һәм һәр чыгарылыш саны, аларның бәясен һәм кайда сатылганлыгын күрсәтеп. |
| | 21. Тираж лотереясының приз фонды средстволары әлеге приз фондына карый торган тираж чикләрендә тулысынча уйнатылырга тиеш, тираж лотереясында билгеләнгән шартлардагы кагыйдәләр буенча тираждан тиражга күчүче суперпризны уйнату очракларыннан тыш. | “Лотереялар турында” Федераль законның 18 статьясы; | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 22.Лотерея билетларындагы мәҗбүри реквизитларга карата таләпләрнең төбәк кызыксындыру лотереясын үткәргәндә лотерея билетларына карата куллана торган шундый ук таләпләргә туры килүен үтәү.<br>Отышны түләүдә, тапшыру яки бирүдә лотерея билетын тәңгәлләштерү (идентификация) кагыйдәләрен үтәү. | “Лотереялар турында” Федераль законның 6 статьясындагы 6 өлешенең 4 пункты, 12 статьясы; Төбәк лотереяларын үткәрүгә төбәк дәүләт контрольлеген хәл итү тәртибенең 5 пунктының 6 абзацы. | Лотерея билеты (квитанция, лотерея шартларында күздә тотылган башка документ) , макеты, аңа карата мәҗбүри таләпләр тасвирламасы белән һәм лотерея билетын ялган билеттан саклау ысуллары зарурилыгы булганда – андагы яшерен язулар, рәсемнәр, билгеләр тасвирламасы белән, кызыксындыру лотересы өчен – кызыксындыру лотереясын оештыручы белән һәм лотереяда катнашучы арасында килешү төзелгәнлекне раслаучы документ (купон, квитанция һ.б.) (лотерея шартларында күздә тотылганда). |
| | 23. Тираж лотереясының һәр тиражының приз фондын уйнату нәтиҗәләре, лотереяны оештыручы тарафыннан әлеге уйнату көненнән соң ун көн эчендә, массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарылырга һәм “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә урнаштырылырга тиеш. | “Лотереялар турында” Федераль законның 18 статьясы; Төбәк лотереяларын үткәрүгә төбәк дәүләт контрольлеген хәл итү тәртибенең 5 пунктының 9 абзацы. | Массакүләм мәгълүмат чараларында һәм “Интернет” челтәрендә басылып чыккан тиражларны үткәрү йомгаклары, тиражларны үткәрүнең рәсми таблицалары, тираж лотереясын үткәрүне туктату турында мәгълүматлар. |
| | 24. Еллык мәҗбүри аудитор тикшерүе. | “Лотереялар турында” Федераль законның 23 статьясы. | Үткәрелгән аудиторлык тикшерүе турында мәгълүматлар. |
| IV. Төбәк тиражсыз лотереяны оештыручылар | 25. Лотереяның приз фонды фәкать лотереяны үткәрүдән кергән керем хисабына гына булдырылырга тиеш.<br>Приз фондының учет һәм аны саклау тәртибе приз фондларын аерым саклау һәм аларның аерым учетын тәэмин итәргә тиеш.<br>Лотереяның приз фонды күләме | “Лотереялар турында” Федераль законның 10,11,17 статьялары; Төбәк лотереяларын үткәрүгә төбәк дәүләт контрольлеген хәл итү тәртибенең 5 | Лотерея үткәрү максатыннан чыгып, лотереяны оештыручы һәм лотерея оештыручы белән лотерея операторы арасында төзелгән килешүләр, шартнамәләр, әлеге килешүләр (шартнамәләр) күчермәләре белән |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | лотереяны үткәрүдән кергән керемгә карата кимендә 50 % тәшкил итәргә тиеш.<br>Приз фонды бурычлар белән чикләнмәгән булырга тиеш, лотереяда катнашучыларга отышлар түләү, тапшыру яки бирү бурычларыннан тыш.<br>Лотереяны оештыручы квартал саен лотерея үткәрүдән кергән керемнең кимендә 10 % ы күләмендә лотереядан максатчан чигерүләрне хәл итәргә тиеш. | пункты. | (күчермәләр нотариуста расланмаган очракта төп нөсхәләрен күрсәтеп).<br>Кредит оешмасы тарафыннан бирелгән, приз фонды суммасын һәм конкрет датага лотерея үткәрүдән (кызыксындыру лотереясыннан тыш) алынган средстволар күләмен раслаган документ.<br>Кредит оешмасы тарафыннан бирелгән, лотереядан максатчан чигерүләр күләмнәрен һәм лотереяны үткәрү (кызыксындыру лотереясыннан тыш) белән бәйле чыгымнарны раслаган документ.<br>Эшләп чыгарылган һәм сатылган лотерея билетларының (башка мәгълүмат чыганаклары) тулаем саны һәм һәр чыгарылыш саны, аларның бәясен һәм кайда сатылганлыгын күрсәтеп.<br>Бухгалтерия хисабы күчермәләре, соңгы хисап датасына һәм узган финанс елы йомгаклары буенча салым органы билгесе белән.<br>Лотереяларны оештыручыларның һәм лотерея операторларының хисаплары күчермәләре.<br>Соңгы хисап датасына финанс (бухгалтерия ) хисабының дөреслеге турында аудитор бәяләмәсенең нотариуста расланган күчермәсе.<br>Лотерея үткәрүгә бәйле чыгымнарны раслаучы документлар. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 26. Лотерея билетларындагы мәҗбүри реквизитларга карата таләпләре төбәк кызыксындыру лотереясын үткәрүгә лотерея билетларына карата куела торган шундый ук таләпләргә туры килүе. | “Лотереялар турында” Федераль законның 12 статьясы; Төбәк лотереяларын үткәрүгә төбәк дәүләт контрольлеген хәл итү тәртибенең 5 пунктының 6 абзацы. | Лотерея билеты (квитанция, лотерея шартларында күздә тотылган башка документ) , макеты, аңа карата мәҗбүри таләпләр тасвирламасы белән һәм лотерея билетын ялган билеттан саклау ысуллары зарурилыгы булганда – андагы яшерен язулар, рәсемнәр, билгеләр тасвирламасы белән, кызыксындыру лотересы өчен – кызыксындыру лотереясын оештыручы белән һәм лотереяда катнашучы арасында килешү төзелгәнлекне раслаучы документ (купон, квитанция һ.б.) (лотерея шартларында күздә тотылганда). |

## 4. Тикшерү үткәрелгәндә юридик зат тарафыннан тапшырыла торган документлар

Тикшерү үткәрү максатларына һәм бурычларына ирешү өчен юридик зат тарафыннан тапшыру зарури булган документлар, шулай ук әлеге документларның формаларын билгеләүче норматив-хокукый актлар исемлеге 2 нче таблицада китерелә.

2 нче таблица. Тикшерү үткәрү максатларына һәм бурычларына ирешү өчен юридик зат тарафыннан тапшырылырга тиешле документлар исемлеге

| № | Тикшерү үткәрү өчен күрсәтелә торган документ | Документ формасын билгеләүче норматив-хокукый акт |
|---|---|---|
| ***Төбәк кызыксындыру лотереясын оештыручыларны һәм операторларны тикшергәндә*** | | |

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Лотерея үткәрүгә рөхсәт күчермәсе | - |
| 2. | Лотереяларны оештыручыларның һәм лотереялар операторларының хисаплар күчермәләре | № 53н РФ Финанс министрлыгы боерыгы |
| 3. | Лотерея үткәрү максатыннан чыгып, лотереяны оештыручы белән лотерея операторы арасында төзелгән килешүләр (шартнамәләр), әлеге килешүләрнең (шартнамәләр) күчермәләре белән (төп нөсхәләрен күрсәтеп) | - |
| 4. | Бухгалтерия хисабы күчермәләре, соңгы хисап датасына һәм узган финанс елы йомгаклары буенча салым органы билгесе белән | № 66н РФ Финанс министрлыгы боерыгы |
| 5. | Соңгы хисап датасына финанс (бухгалтерия) хисабының дөреслеге турында аудитрлык бәяләмәсе күчермәсе | - |
| 6. | Лотерея үткәрүгә бәйле чыгымнарны раслаучы документлар | - |
| 7. | Лотерея җиһазының тасвирламасы һәм техник характеристикалары (кулланылыштагы программаның контроль суммаларын күрсәтеп, эксплуатация документларын һәм әлеге программада декларацияләнмәгән мөмкинлекләрнең булмавына контрольлек таләпләрен үтәүне раслаучы документны кертеп | - |
| 8. | Лотерея билеты макеты (лотерея шартларында күздә тотылганда) | - |
| 9. | Реклама чараларын үткәрү чараларында реклама белдерүе тексты | - |
| 10. | Тулаем алганда бер ел эчендә һәм лотереяның һәр чыгарылышы буенча түләнгән отышлар күләме һәм суммасы турында, аларны бирү өчен билгеләнгән срок чыкканнан соң, шулай ук аларны алу өчен дәгъва белдерү срогы чыкканнан соң сорап алынмаган отышлар күләме һәм суммасы турында мәгълүматлар | |
| 11. | Кызыксындыру лотереясын үткәрүне туктату турында хәбәрләрне массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару турында мәгълүматлар | - |
| | ***Төбәк тираж лотереясын оештыручыларны һәм операторларны тикшергәндә*** | |
| 1. | Лотерея үткәрүгә рөхсәт күчермәсе | - |
| 2. | Лотереяларны оештыручыларның һәм лотереялар операторларының хисаплар күчермәләре | № 53н РФ Финанс министрлыгы боерыгы |
| 3. | Тираж комиссиясе составы турында мәгълүмат.<br>Тираж лотереясының приз фондын уйнату йомгаклары буенча тираж комиссиясе беркетмәсе | - |
| 4. | Лотерея үткәрү максатыннан чыгып, лотереяны оештыручы белән лотерея операторы арасында төзелгән килешүләр (шартнамәләр), әлеге килешүләрнең (шартнамәләр) күчермәләре белән (төп нөсхәләрен күрсәтеп) | - |
| 5. | Кредит оешмасы (яки лотерея оештыручының һәм лотерея оераторының расчет счетлары белән идарә итүче башка оешма) биргән, приз фонды суммасын һәм конкрет датага лотерея үткәрүдән алынган средстволарның | № 53н РФ Финанс министрлыгы боерыгы |

| | | |
|---|---|---|
| | гомуми күләмен раслаган документ | |
| 6. | Эшләп чыгарылган һәм сатылган лотерея билетларының (башка мәгълүмат чыганаклары) тулаем санын һәм һәр чыгарылыш санын раслаучы документлар, аларның бәясен һәм кайда сатылганлыгын күрсәтеп | - |
| 7. | Бухгалтерия хисабы күчермәләре, соңгы хисап датасына һәм узган финанс елы йомгаклары буенча салым органы билгесе белән | № 66н РФ Финанс министрлыгы боерыгы |
| 8. | Соңгы хисап датасына финанс (бухгалтерия) хисабының дөреслеге турында аудитрлык бәяләмәсе күчермәсе. Лотерея үткәрүгә бәйле чыгымнарны раслаучы документлар | - |
| 9. | Лотерея җиһазының тасвирламасы һәм техник характеристикалары (кулланылыштагы программаның контроль суммаларын күрсәтеп, эксплуатация документларын һәм әлеге программада декларацияләнмәгән мөмкинлекләрнең булмавына контрольлек таләпләрен үтәүне раслаучы документны кертеп) | - |
| 10. | Лотерея билеты макеты, ялган билеттан саклану элементлары тасвирламасы белән | - |
| 11. | Массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыккан тиражларны үткәрү йомгаклары, тиражларны үткәрүнең рәсми таблицалары турында мәгълүматлар | - |
| 12. | Кредит оешмасы тарафыннан бирелгән, лотереядан максатчан чигерүләр күләмнәрен һәм лотерея үткәрү белән бәйле чыгымнар күләмен раслаган документ | - |
| 13. | Тулаем алганда бер ел эчендә һәм лотереяның һәр чыгарылышы буенч атүләнгән отышлар күләме һәм суммасы турында, аларны бирү өчен билгеләнгән срок чыкканнан соң, шулай ук аларны алу өчен дәгъва белдерү срогы чыкканнан соң сорап алынмаган отышлар күләме һәм суммасы турында мәгълүматлар | - |
| 14. | Һәр чыгарылыш буенча (кызыксындыру лотереяларыннан тыш) сатылмый калган һәм юкка чыгарлыган билетлар турында актлар | - |
| | ***Төбәк тиражсыз лотерея оештыручыларны һәм операторларны тикшергәндә*** | |
| 1. | Лотерея үткәрүгә рөхсәт күчермәсе | - |
| 2. | Лотереяларны оештыручыларның һәм лотереялар операторларының хисаплар күчермәләре | № 53н РФ Финанс министрлыгы боерыгы |
| 3. | Лотерея үткәрү максатыннан чыгып, лотереяны оештыручы белән лотерея операторы арасында төзелгән килешүләр (шартнамәләр), әлеге килешүләрнең (шартнамәләр) күчермәләре белән (төп нөсхәләрен күрсәтеп) | - |
| 4. | Кредит оешмасы (яки лотерея оештыручының һәм лотерея операторының расчет счетлары белән идарә итүче башка оешма) биргән, приз фонды суммасын һәм конкрет датага лотерея үткәрүдән алынган средстволарның гомуми күләмен раслаган документ | № 53н РФ Финанс министрлыгы боерыгы |
| 5. | Эшләп чыгарылган һәм сатылган лотерея билетларының (башка мәгълүмат чыганаклары) тулаем санын һәм һәр чыгарылыш санын раслаучы документлар, аларның бәясен һәм кайда сатылганлыгын күрсәтеп | - |

| | | |
|---|---|---|
| 6. | Бухгалтерия хисабы күчермәләре, соңгы хисап датасына һәм узган финанс елы йомгаклары буенча салым органы билгесе белән | - |
| 7. | Соңгы хисап датасына финанс (бухгалтерия) хисабының дөреслеге турында аудитрлык бәяләмәсе күчермәсе. Лотерея үткәрүгә бәйле чыгымнарны раслаучы документлар | - |
| 8. | Лотерея җиһазының тасвирламасы һәм техник характеристикалары (кулланылыштагы программаның контроль суммаларын күрсәтеп, эксплуатация документларын һәм әлеге программада декларацияләнмәгән мөмкинлекләрнең булмавына контрольлек таләпләрен үтәүне раслаучы документны кертеп) | - |
| 9. | Лотерея билеты макеты (лотерея шартларында күздә тотылганда) | - |
| 10. | Кредит оешмасы тарафыннан бирелгән, лотереядан максатчан чигерүләр күләмнәрен һәм лотерея үткәрү белән бәйле чыгымнар күләмен раслаган документ | - |
| 11. | Тулаем алганда бер ел эчендә һәм лотереяның һәр чыгарылышы буенча түләнгән отышлар күләме һәм суммасы турында, аларны бирү өчен билгеләнгән срок чыкканнан соң, шулай ук аларны алу өчен дәгъва белдерү срогы чыкканнан соң сорап алынмаган отышлар күләме һәм суммасы турында мәгълүматлар | - |
| 12. | Һәр чыгарылыш буенча сатылмый калган һәм юкка чыгарлыган билетлар турында актлар | - |

## 5. Административ процедуралар (гамәлләр) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон рәвештә административ процедуралар (гамәлләр) үтәү үзенчәлекләре

Дәүләт вазыйфасын үтәү түбәндәге тикшерүләр төрләрен үткәрү юлы белән хәл ителә:

–юридик затларны планлы (документар, күчмә) тикшерүләр;

–юридик затларны планнан тыш (документар, күчмә) тикшерүләр.

Бу Регламент түбәндәге административ процедуралар үтәүне күздә тота:

юридик затка планлы документар тикшерү үткәрү;

юридик затка планлы күчмә тикшерү үткәрү;

юридик затка планнан тыш документар тикшерү үткәрү;

юридик затка планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү.

Дәүләт вазыйфасын үтәүнең блок-схемасы бу Регламентка № 9 кушымтада китерелә.

Дәүләт вазыйфасын үтәүне туктатып тору Россия Федерациясе законында күздә тотылмаган.

5.1. “Юридик затка планлы документар тикшерү үткәрү” административ процедурасы

5.1.1. “Юридик затка планлы документар тикшерү үткәрү” административ процедурасын башлауга нигез булып тиешле юридик затны еллык планга кертү тора.

Юридик затны планлы тикшерүне еллык планга кертү бу Регламентның 2.4.1 пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча хәл ителә.

5.1.2. “Юридик затка планлы документар тикшерү үткәрү” административ процедурасы түбәндәге гамәлләр тәртибе нигезендә хәл ителә:

планлы документар тикшерү үткәрүгә җаваплы вазыйфаи затларны билгеләү;

планлы документар тикшерү үткәрү турында боерык рәсмиләштерү;

планлы документар тикшерү үткәрү турында юридик затка уведомление җиткерү;

планлы документар тикшерү үткәрү;

планлы документар тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү.

5.1.3.Тикшерү үткәргече Бүлек начальнигы еллык план нигезендә юридик затка планлы документар тикшерү үткәрүгә җаваплы зат (җаваплы затлар) (җаваплы эш башкаручы) билгели.

Үтәү срогы: планлы документар тикшерү үткәрү башланырга ун эш көне кала.

Гамәл нәтиҗәсе: планлы документар тикшерү үткәрүне хәл итү өчен җаваплы эш башкаручыны билгеләү.

5.1.4.Җаваплы эш башкаручы юридик затка планлы документар тикшерү үткәрү турында боерык әзерли һәм аны министрга (министрның беренче урынбасары) имза салуга җибәрә (бу Регламентка № 7 кушымта)

тикшерү үткәрү турында боерыкның типовой формасы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 30.04.2009 ел, №141 боерыгы белән расланган).

Үтәү срогы: планлы документар тикшерү үткәрү башланырга сигез эш көне кала.

Гамәл нәтиҗәсе: планлы документар тикшерү үткәрү турында министр (министрның беренче урынбасары) имзалаган боерык.

5.1.5.Җаваплы эш башкаручы планлы документар тикшерү үткәрү турында боерык күчермәсен почта аша җибәрү юлы белән, тапшыру турында уведомление белән, яки уңайлы башка ысул белән (телефон элемтәсе) (телефонограмма), факсимиль элемтә (факсограмма), электрон почта аша, алу турында билге белән, кулына тапшырып) планлы документар тикшерү үткәрү турында юридик затка хәбәр җиткерә.

Юридик затка планлы документар тикшерү үткәрү турында боерык күчермәсен җибәрү Департаментта делопроизводствоны алып бару кагыйдәләре нигезендә билгеләнгән тәртиптә теркәлә.

Үтәү срогы: планлы документар тикшерү үткәрү башланырга өч эш көне кала.

Гамәл нәтиҗәсе: планлы документар тикшерү үткәрү турында боерык күчермәсен юридик затка җибәрү.

5.1.6.Юридик зат уведомление алганнан соң ун эш көне эчендә Департаментка тикшерү үткәрү турында боерык күчермәсендә күрсәтелгән документларның күчермәләрен (юридик зат мөһере (булганда), җитәкчесе, башка вазыйфаи заты имзасы белән расланган) җибәрергә тиеш.

Юридик зат запроста күрсәтелгән документларны электрон документлар рәвешендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә тапшыруга хокуклы.

5.1.7.Җаваплы эш башкарчы документар тикшерү үткәрү процессында иң элек Департаментка билгеләнгән тәртиптә тапшырылган, Департамент карамагындагы юридик зат документларын, алдагы тикшерүләр актларын, административ хокук бозулар турында эшләрне карап тикшерү материалларын һәм әлеге юридик затка карата элегрәк хәл ителгән тикшерүләр нәтиҗәләре турында башка документларны тикшерә.

Җаваплы эш башкаручы бәяли:

–Департамент карамагындагы документлардагы мәгълүматларның һәм юридик зат тапшырган документлардагы мәгълүматларның дөреслеген;

–юридик зат тапшырган документлардагы мәгълүматларның лотереялар турында Федераль закон нигезендә билгеләнгән мәҗбүри таләпләргә туры килү-килмәвен.

Документар тикшерү барышында юридик зат тарафыннан тапшырылган документларда хаталар һәм (яки) туры килмәүләр яисә бу документлардагы мәгълүматларның Департамент карамагындагы мәгълүматларга туры килмәве ачыкланган очракта җаваплы эш башкаручы юридик затка тапшырылган мәгълүматларның туры килмәве турында, министр (министрның беренче урынбасары) имзалаган хат алынганнан соң ун эш көне эчендә язмача аңлатмалар тапшыру таләбе белән, хат (нигезле запрос) җибәрә. Хат (нигезле запрос) юридик затка почта аша заказлы хат белән, тапшыру турында уведомление белән, яки уңайлы башка ысул

белән факсимиль элемтә, электрон почта, алу турында билге белән кулга тапшырып җибәрә.

Хат (нигезле запрос) җибәрү Департаментта делопроизводство алып бару кагыйдәләре нигезендә билгеләнгән тәртиптә теркәлә.

Департаментка тапшырылган документларда ачыкланган хаталарга һәм (яки) туры килмәүләргә карата яисә әлеге документлардагы мәгълүматлардагы Департамент карамагындагы документларга туры килмәвенә карата аңлатмалар тапшыручы юридик зат элек тапшырылган документларның дөреслеген раслаучы өстәмә документлар тапшыруга хокуклы.

Документар тикшерү барышында югарыда күрсәтеп үтелгән хаталар һәм (яки) туры килмәүләр ачыкланмаган очракта җаваплы эш башкаручы юридик затның бозуларсыз эшчәнлеген чагылдыручы тикшерү актын төзи.

Үтәү срогы: тикшерү үткәрү башланганнан соң биш эш көне эчендә.

Гамәл нәтиҗәсе: юридик затка карап тикшерү өчен кирәкле башка документларны тапшыру таләбе белән хат (нигезле запрос) яки юридик затның бозуларсыз эшчәнлеген чагылдыручы тикшерү акты.

5.1.8.Җаваплы эш башкаручы аңлатмалар һәм (яки) элегрәк тапшырылган документларның дөреслеген раслаучы документлар алганнан соң юридик зат тапшырган аңлатмаларны һәм (яки) элек тапшырылган документларның дөреслеген раслаучы документларны тикшерә һәм юридик зат документларындагы мәгълүматларга бәяләмә бирә.

Департамент тапшырылган аңлатмаларны һәм (яки) элегрәк тапшырылган документларның дөреслеген раслаучы документларны карап тикшергәннән соң мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләрен ачыкласа яки аңлатмалар булмаса департаментның вазыйфаи затлары күчмә тикшерү үткәрүгә хокуклы. Күчмә тикшерү үткәрү турында карарны министр (министрның беренче урынбасары) кабул итә. Бу очракта планлы документар тикшерү нәтиҗәсе “Юридик затка планлы күчмә тикшерү үткәрү” административ процедурасын үтәүне башлау өчен нигезгә туры килә.

Күчмә тикшерү бу Регламентның 5.2.2 пунктында китерелгән тәртиптә хәл ителә.

Үтәү срогы: аңлатмалар алынганнан соң биш эш көне эчендә.

Гамәл нәтиҗәсе: юридик зат тарафыннан тапшырылган аңлатмаларны һәм (яки) документларны җаваплы эш башкаручының тикшерүе.

5.1.9.Тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү тикшерү тәгәлләнгәннән соң турыдан-туры хәл ителә.

Бозулар билгеләнмәгән очракта юридик затның бозуларсыз эшчәнлеген чагылдыручы тикшерү акты төзелә.

Җаваплы эш башкаручы күзәтчелек чаралары нәтиҗәсендә мәҗбүри таләпләрне бозулар ачыклаган очракта:

–тикшерү акты төзи, анда ачыкланган барлык бозулар очракларын терки;

–лотереяны оештыручыга лотереяны оештыручы тарафыннан түбәндәге шартлар санга сугылмаган очракта күрсәтмә бирә:

а)лотерея оештыручы Департаментка тулы булмаган яки дөрес булмаган мәгълүмат тапшырганда;

б)лотереяны оештыручы ачыкланган бозуны лотереяны оештыручы тарафыннан билгеләнгән срокта юкка чыгару турында Департамент карарын үтәмәгәндә;

–әлеге күрсәтмәләрнең билгеләнгән срокта үтәлүен контрольдә тота;

–РФ КоАП күздә тотылган административ хокук бозу билгеләре ачыкланганда административ хокук бозулар турында эшләр кузгата һәм административ хокук бозу турында беркетмә төзелгәннән соң өч көн эчендә аны, билгеләнгән тәртиптә карап тикшерү өчен, суд органына җибәрә;

–тикшерү үткәрү барышында төбәк лотереясын оештыручыга бирелгән лотереяны үткәрүгә рөхсәтне кире алу өчен нигез булып торган хәлләр ачыкланган очракта лотерея үткәрүгә рөхсәтне кире алу турында судка гариза проекты әзерли;

–рөхсәт законлы көченә кергәнче, лотереяны үткәрүгә рөхсәтнең гамәлдә булуын (кызыксындыру лотереясының гамәлдә булуын) туктатып тору турында карар әзерли ала;

–лотереяны оештыручыга лотереяны үткәрүгә рөхсәтнең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм, мондый карарларны нигезләп, язмача рәвештә әлеге рөхсәтне кире алу турында судка гариза җибәрү турында карар җибәрә.

Контрольлек чарасы барышында контрольлек чарасын үткәрү объекты булып торучы хуҗалык эшчәнлегенең яки башка эшчәнлекнең Министрлык компетенциясенә керми торган закон таләпләрен закон таләпләрен бозуларга бәйле булуы ачыкланган очракта Министрлык Россия Федерациясе яки Татарстан Республикасының тиешле вәкаләтле дәүләт хакимияте органнарына мондый бозулар турында мәгълүмат (мәгълүматлар) җибәрүгә бурычлы.

Төбәк лотореясын үткәрүгә рөхсәтне кире алу турында гариза белән судка мөрәҗәгать итүгә нигез булып түбәндәге шартлар тора:

1) лотерея оештыручы тарафыннан Департаментка тулы булмаган яки дөрес булмаган мәгълүмат тапшыру;

2) лотерея оештыручының ачыкланган бозуны лотерея оештыручы тарафыннан билгеләнгән срокта юкка чыгару турында Департамент карарын үтәмәү яки түбәндәге бозуларның ачыклануы:

– төбәк лотереясын үткәрүдән алынган средстволардан максатчан файдаланмау. Средстволардан максатчан файдаланмау төбәк лотереясыннан максатчан чигерүләрне “Лотереялар турында” Федераль законның 11 статьясында күздә тотылмаган максатларга җибәрелүен, шулай ук төбәк лотереясында катнашучыга отышны түләмәү, тапшырмау яки бирмәүне аңлата;

– “Лотереялар турында” Федераль закон таләпләрен һәм лотерея шартларын төбәк лотерея оештыручы тарафыннан бозу;

– “Лотереялар турында” Федераль законның 10 статьясында билгеләнгән төбәк лотереясенең мәҗбүри нормативларын үтәмәү.

Лотерея үткәрүгә рөхсәтне кире алу турында гаризаны министр (министрның беренче урынбасары) имзалый.

Департамент судка гариза тапшыру белән бер үк вакытта суд карары законлы көченә кергәнче лотерея үткәрүгә рөхсәтнең гамәлдә булуын туктатып торуга хокуклы.

Төбәк лотереясын үткәрүгә рөхсәтнең гамәлдә булуын туктатып тору турында карарны министр (министрның беренче урынбасары) имзалый.

Тикшерү актын төзү өчен үткәрелгән тикшеренүләр, сынаулар, махсус тикшерүләр, экспертизалар нәтиҗәләре буенча бәяләмә алырга кирәк булган очракта тикшерү акты күзәтчелек чарасы тәгәлләнгәннән соң өч эш көненнән дә артмаган срокта тутырыла.

Эш хәлләрен өстәмә ачыклау яки административ хокук бозу турында үзенә карата эш кузгатылган лотереяны оештыручы турында мәгълүматлар алу таләп ителгән очракта административ хокук бозу турында беркетмә административ хокук бозу ачыкланганнан соң ике тәүлек эчендә тутырыла.

Лотереяны оештыручы Департаментка бозуларны юкка чыгару турында күрсәтмә алынганнан соң күрсәтмәдә билгеләнгән 30 календарь көненнән дә артмаган срокта җиткерә.

Җаваплы эш башкаручы тикшерү актының бер нөсхәсен (кушымталары белән бергә) делога тегеп куя, икенче нөсхәсен (кушымталары белән бергә), тикшерү акты белән танышу турында яки танышудан баш тарту турында имза салдырып, юридик зат җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә тапшыра.

Юридик зат җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, шулай ук тикшерелә торган зат тикшерү акты белән танышу турында яки танышудан баш тарту турында имза салудан баш тарткан очракта акт тикшерү тәгәлләнгәннән соң бер эш көне эчендә почта аша заказлы хат белән, тапшыру турында уведомление белән җибәрелә, ул Департаменттагы делода саклана торган тикшерү акты нөсхәсе янына куела.

Үтәү срогы:

– тикшерү актын, административ хокук бозу турында беркетмә, ачыкланган бозуларны юкка чыгару турында күрсәтмәләрне төзү һәм юридик затка тапшыру: турыдан-туры тикшерү тәгәлләнгәннән соң (әлеге документларны заказлы хат белән җибәрү: күзәтчелек чаралары тәгәлләнгәннән соң бер эш көне эчендә);

– лотерея оештыручыга лотерея үткәрүгә рөхсәтнең гамәлдә булуын туктатып торуы турында карар һәм әлеге рөхсәтне кире алу турында судка гариза җибәрү хакында карар җибәрү – аларны кабул иткәннән соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча;

– административ хокук бозулар турында беркетмәләрне билгеләнгән тәртиптә карап тикшерү өчен суд органына җибәрү – административ хокук бозу турында беркетмә төзегәннән соң өч эш көне эчендә;

– лотерея үткәрүгә рөхсәтне кире алу турында судка гариза җибәрү – тикшерү акты тутырылганнан соң ун эш көне эчендә.

Гамәл нәтиҗәсе: тикшерү акты, административ хокук бозу турында беркетмә тутыру, ачыкланган бозуларны юкка чыгару турында күрсәтмә, лотерея үткәрүгә рөхсәтне кире алу турында судка гариза, суд карары законлы көченә кергәнче, лотерея үткәрергә рөхсәтнең гамәлдә булуын

(кызыксындыру лотереясының гамәлдә булуын) туктатып тору турында карар.

Барлык документлар ике нөсхәдә тутырыла, аларның берсе юридик затка тапшырыла (җибәрелә), икенчесе делога тегеп куела.

5.1.10. “Юридик затка планлы документар тикшерү үткәрү” административ процедурасын үтәү нәтиҗәсе Министрлыкның рәсми сайтында электрон рәвештә теркәлә.

5.2. “Юридик затка планда каралган күчмә тикшерү үткәрү” административ процедурасы

5.2.1. “Юридик затка планда каралган күчмә тикшерү үткәрү” административ процедурасы башлауга нигез булып тиешле юридик затны еллык планга кертү тора, шулай ук документар тикшерү вакытында түбәндәгеләргә ирешү мөмкин булмаганда:

– юридик затның Департамент карамагындагы документларындагы мәгълүматларның тулылыгын һәм дөреслеген дәлилләү;

– юридик зат эшчәнлегенең тиешле контрольлек чарасы үткәрмичә генә мәҗбүри таләпләргә туры килүен бәяләү мөмкин булмаганда үткәрелә.

Юридик затка планда каралган тикшерү үткәрүне еллык планга кертү бу Регламентның 2.4.1 пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча хәл ителә.

5.2.2. “Юридик затка планда каралган күчмә тикшерү үткәрү” административ процедурасы түбәндәге гамәлләр нигезендә хәл ителә:

планда каралган күчмә тикшерү үткәрүгә җаваплы вазыйфаи затларны билгеләү;

планда каралган күчмә тикшерү үткәрү турында боерык рәсмиләштерү;

планда каралган күчмә тикшерү үткәрү турында юридик затка хәбәр җиткерү;

планда каралган күчмә тикшерү үткәрү;

планда каралган күчмә тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү.

5.2.3. Юридик затка планда каралган күчмә тикшерү үткәрү өчен җаваплы эш башкаручыны билгеләү, министр (министрның беренче урынбасары) боерыгын, тикшерү үткәрү турында юридик затка уведомление әзерләү бу Регламентның 5.1.3-5.1.5 пунктчаларында күздә тотылган тәртиптә хәл ителә.

Тикшерү үткәрү өчен экспертлар, эксперт оешмалары катнашында контрольлек чаралары үткәрү таләп ителгән очракта үзенә карата тикшерү үткәрелә торган юридик зат белән гражданлык-хокукый һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаган һәм тикшерелә торган юридик зат белән аффиллирланган затлар булып тормаган экспертлар, эксперт оешмалары вәкилләре җәлеп ителә.

5.2.4. Җаваплы эш башкаручы, экспертлар, эксперт оешмалары вәкилләре юридик зат объектына килгәннән соң тикшерүне башлый:

– хезмәт таныклыкларын күрсәтеп:

– юридик зат җитәкчесен яки башка вазыйфаи затын, аның вәкаләтле вәкилен күчмә тикшерү билгеләү турында һәм министр боерыгы белән таныштырып;

– юридик зат җитәкчесен яки башка вазыйфаи затын, вәкаләтле вәкилен күчмә тикшерүне үткәрүче затларның вәкаләтләре белән, шулай ук күчмә тикшерү үткәрү максатлары, бурычлары, нигезләре һәм контрольлек чаралары күләмнәре, күчмә тикшерүгә җәлеп ителә торган экспертлар составы, экспертлар оешмалары вәкилләре, тикшерү үткәрү сроклары һәм шартлары белән мәҗбүри таныштырып.

Җаваплы эш башкаручы юридик зат эшчәнлегенең бу Регламентның 3 бүлегендә китерелгән мәҗбүри таләпләргә туры килүен бәяли.

Планлы күчмә тикшерү үткәргәндә юридик зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозулар ачыкланган очракта җаваплы эш башкаручы мәҗбүри таләпләрне бозуга җаваплы юридик зат хезмәткәрләреннән аңлатмалар соратып ала.

Үтәү срогы: юридик затка планда каралган күчмә тикшерү үткәрүнең гомуми срогы – күп дигәндә егерме эш көне.

Гамәл нәтиҗәсе: юридик зат эшчәнлегенең мәҗбүри таләпләргә туры килүен бәяләү максатыннан чыгып, планда каралган күчмә тикшерү үткәрү.

5.2.5. Планлы күчмә тикшерү үткәрү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү бу Регламентның 5.1.9 пункты нигезендә хәл ителә.

Тикшерү актына мәҗбүри таләпләрне бозуга җаваплы юридик зат хезмәткәрләренең аңлатмалары һәм тикшерү нәтиҗәләре белән бәйле башка документлар яки аларның күчермәләре кушып бирелә.

Җаваплы эш башкаручы тикшерүләрнең учет журналын алып баруны тикшерә, журналның битләренең тегелгән, номер сугылган һәм юридик зат мөһере белән расланган булуы-булмавын тикшерә.

Тикшерүнең үткәргән җаваплы эш башкаручы, шулай ук тикшерү үткәрүгә җәлеп ителгән эксперт оешмасы вәкиле тикшерүләрнең учет журналына язып куя. Тикшерүләрнең учет журналы булмаганда тикшерү актына тиешенчә язып куела.

5.2.6. “Юридик затка планлы күчмә тикшерү үткәрү” административ процедурасын үтәү нәтиҗәсе Министрлыкның рәсми сайтында электрон рәвештә теркәлә.

5.3. “Юридик затка планнан тыш документар тикшерү үткәрү” административ процедурасы

5.3.1. “Юридик затка планлы күчмә тикшерү үткәрү” административ процедурасын башлауга нигез булып бу Регламентның 2.4.2 пунктында күрсәтелгән очраклар тора.

Планнан тыш документар тикшерү Министрлыкның урнашу урыны буенча үткәрелә.

5.3.2. “Юридик затка планлы күчмә тикшерү үткәрү” административ процедурасы түбәндәге гамәлләр тәртибе нигезендә хәл ителә:

Планнан тыш документар тикшерү үткәрүгә җаваплы вазыйфаи затларны билгеләү;

планнан тыш документар тикшерү үткәрү турында боерык рәсмиләштерү;;

планнан тыш документар тикшерү үткәрү;

планнан тыш документар нәтиҗәләрен рәсмиләштерү.

5.3.3. Министр (министрның беренче урынбасары) бу Регламентның 2.4.2 пунктында күрсәтелгән планнан тыш тикшерү үткәрүгә нигезләр килеп чыкканда Бүлек начальнигына планнан тыш документар тикшерү оештыруны һәм үткәрүне йөкли. Бүлек начальнигы юридик затка планнан тыш документар тикшерү үткәрү өчен җаваплы эш башкаручыны билгели.

Үтәү срогы: планнан тыш документар тикшерү үткәрүгә нигезләр килеп чыкканнан соң бер эш көне эчендә.

Гамәл нәтиҗәсе: юридик затка планнан тыш документар тикшерү үткәрү өчен җаваплы эш башкаручыны билгеләү.

5.3.4. Планнан тыш документар тикшерү үткәрү турында боерык рәсмиләштерү, планнан тыш документар тикшерү үткәрү (юридик зат документларындагы мәгълүматларны бәяләү, язмача рәвештә кирәкле аңлатмалар бирүне таләп итеп, юридик затка хат (нигезле запрос) җибәрү, юридик затның тапшырылган документлардагы искәртүләргә аңлатмаларын карап тикшерү, шулай ук планнан тыш документар тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү бу Регламентның 5.1.4, 5.1.6-5.1.9 пунктчаларында билгеләнгән тәртиптә хәл ителә.

5.3.5. “Юридик затка планнан тыш документар тикшерү үткәрү” административ процедурасын үтәү нәтиҗәсе Министрлыкның рәсми сайтында электрон рәвештә теркәлә.

5.4. “Юридик затка планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү” административ процедурасы

5.4.1. “Юридик затка планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү” административ процедурасын башлауга нигез булып бу Регламентның 2.4.2 пунктында күрсәтелгән очраклар тора, шулай ук документар тикшерү вакытында түбәндәгеләргә ирешү мөмкин булмаганда:

1) Департамент карамагындагы юридик зат документларындагы мәгълүматларның тулылыгы һәм дөреслеген дәлилләү;

2) юридик зат эшчәнлегенең тиешле контрольлек чарасы үткәрмичә мәҗбүри таләпләргә туры килүен бәяләү мөмкин булмаганда үткәрелә.

5.4.2. “Юридик затка планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү” административ процедурасы 5.2.2 пунктта күрсәтелгән гамәлләр тәртибе нигезендә хәл ителә.

5.4.3. Юридик затка планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү өчен җаваплы эш башкаручыны билгеләү бу Регламентның 5.3.3 пункты нигезендә хәл ителә.

5.4.4. Юридик затка планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында боерыкны рәсмиләштерү бу Регламентның 5.1.4 пункты нигезендә хәл ителә.

Тикшерү үткәрү өчен экспертлар, эксперт оешмалары катнашында контрольлек чаралары үткәрү таләп ителгән очракта үзенә карата тикшерү үткәрелә торган юридик зат белән гражданлык-хокукый һәм хезмәт

мөнәсәбәтләрдә тормаган һәм тикшерелә торган юридик зат белән аффилирлы зат булып тормаган экспертлар, эксперт оешмалары вәкилләре җәлеп ителә.

5.4.5. Бу Регламентның 2.4.2 пунктындагы “б” пунктчасында күрсәтелгән нигез буенча планнан тыш күчмә тикшерү Департамент тарафыннан, №294-ФЗ Федераль законның 10 статьясындагы 12 өлешендә билгеләнгән тәртиптә, прокуратура органына хәбәр итеп кичекмәстән үткәрелергә мөмкин.

Планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүгә нигез булып бу Регламентның 2.4.2 пунктындагы “б” пунктчасында күрсәтелгән нигез торган очракта, җаваплы эш башкаручы:

– юридик затка планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне килештерү турында юридик зат эшчәнлеген хәл итү урыны буенча прокуратура органына гариза әзерли һәм аңа министрдан (министрның беренче урынбасары) имза салдыра (бу регламентка № 8 кушымта, планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне прокуратура органы белән килештерү турында гаризаның типовой формасы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 30.04.2009 ел, № 141 боерыгы белән расланган);

– юридик зат эшчәнлеген хәл итү урыны буенча прокуратура органына планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне килештерү турында гариза тапшыра яки почта аша заказлы хат белән, тапшыру турында уведомление белән, яки электрон санлы имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрә. Әлеге гаризага планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында министрның (министрның беренче урынбасары) боерыгы күчермәсе һәм тикшерү үткәрүгә нигез булып хезмәт иткән мәгълүматлардан торган документлар кушып бирелә.

5.4.6. Җаваплы эш башкаручы планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында юридик затка (бу Регламентның 2.4.2 пунктының “б” пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүдән тыш) тикшерү башланырга кимендә 24 сәгать кала уңайлы теләсә кайсы юл белән (телефон элемтәсе (телефонограмма), факсимиль элемтә (факсограмма), электрон почта аша, алу турында билге белән кулга тапшырып) хәбәр җиткерә.

Бу регламентның 2.4.2 пунктының “б” пунктчасында күрсәтелгән нигез буенча планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында юридик затка баштан хәбәр җиткереп кую рөхсәт ителми.

Үтәү срогы: тикшерү башланырга ким дигәндә егерме дүрт сәгать кала.

Гамәл нәтиҗәсе: юридик затка тикшерү үткәрү турында хәбәр җиткерү.

5.4.7. Планнан тыш күчмә тикшерү бу регламентның 5.2.4 пунктында билгеләнгән тәртиптә үткәрелә.

5.4.8. Тикшерү актын тутыру бу Регламентның 5.1.9 пункты нигезендә хәл ителә.

Янә ачыкланган бозулар, шулай ук системалы характер алган бозулар очраклары мәҗбүри рәвештә теркәп куела.

Планнан тыш күчмә тикшерү прокуратура органы белән килештереп үткәрелгән очракта планнан тыш күчмә тикшерү акты күчермәсе тикшерү

үткәрүне килештерү турында карар кабул иткән прокуратура органына тикшерү акты тутырылганнан соң биш эш көне эчендә җибәрелә.

5.4.9. "Юридик затка планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү" административ процедурасын үтәү нәтиҗәсе Министрлыкның рәсми сайтында электрон рәвештә теркәлә.

## 6. Дәүләт вазыйфасын үтәү тәртибе һәм аның үтәүгә контрольлек формалары

6.1. Министрлык вазыйфаи затлар тарафыннан үзләренең хезмәт бурычларын үтәвенә контрольлек итә, тикшерүләр үткәрү барышында вазыйфаи затлар тарафыннан үз вәкаләтләрен тиешенчә үтәмәү очракларын учетка алып бара, хезмәт урынында тиешле тикшерелүләр үткәрә һәм Россия Федерациясе законы нигезендә вазыйфаи затларга карата чаралар күрә.

6.2. Бу Регламентның үтәлешенә контрольлекне министр (министрның беренче урынбасары) хәл итә.

6.3. Дәүләт вазыйфасын үтәү буенча гамәлләр срокларының, эзлеклелегенең үтәлешенә һәм Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан аны үтәү барышында кабул ителгән карарларга агымдагы контрольлекне министрның беренче урынбасары һәм Министрлыкның вәкаләтле хезмәткәрләре хәл итә.

6.4. Дәүләт вазыйфасын үтәүгә агымдагы контрольлекне хәл итүгә вәкаләтле Министрлык хезмәткәрләре исемлеге, әлеге контрольлекне хәл итү тәртибе һәм вакыт аралыклары Министрлык актлары белән билгеләнә. Агымдагы контрольлекне хәл итүгә Министрлык хезмәткәрләренең вәкаләтләре, Министрлыкның структур подразделениеләре турында нигезләмәләрдә, хезмәткәрләрнең вазыйфаи структур инструкцияләрендә билгеләнә.

6.5. Агымдагы контрольлек бу регламент нигезләмәләрен һәм дәүләт вазыйфасын үтәүгә карата таләпләрне билгеләүче башка норматив-хокукый актлар нигезләмәләрен үтәүгә тикшерүләр үткәрү юлы белән хәл ителә. Тикшерүләр үткәрүнең тулылыгы һәм сыйфатына агымдагы контрольлек даими нигездә хәл ителә һәм мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын бозуларны ачыклау һәм билгеләүне, тиешле бозуларны юкка чыгару турында карарлар кабул итүне үз эченә ала.

6.6. Дәүләт вазыйфасын үтәүгә контрольлек итү планлы һәм планнан тыш тикшерүләр үткәрүне үз эченә ала.

Дәүләт вазыйфасын үтәүнең тулылыгы һәм сыйфатына планлы тикшерүләр агымдагы елга Министрлыкның еллык эш планы нигезендә үткәрелә. Планлы тикшерүләр әлеге планга Бүлек начальнигы белән килештереп министрның беренче урын басары тарафыннан кертелә.

Планнан тыш тикшерүләр элегрәк ачыкланган бозуларны юкка чыгаруны тикшерүгә бәйле рәвештә, шулай ук Министрлык бүлекләренең вазыйфаи затлары тарафыннан үзләренең вазыйфаи бурычлары үтәүдәге гамәлләренә (гамәл кылмау), шикаятьләр нигезендә үткәрелә.

6.7. Дәүләт вазыйфасын үтәүгә җаваплы булган Министрлыкның вазыйфаи затлары дәүләт вазыйфасын үтәү барышында үзләре тарафыннан кылган гамәлләргә (гамәл кылмау), кабул ителгән карарларга җавап бирә.

Министрлыкның вазыйфаи затларының җаваплылыгы үзләренең вазыйфаи инструкцияләрендә Россия Федерациясе закон таләпләре нигезендә билгеләнә.

Министрлык Россия Федерациясе законын бозган гаепле вазыйфаи затларга карата күрелгән чаралар турында мондый чаралар күрелгәннән соң ун көн эчендә үзенең хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре санга сугылмаган лотерея оештыручыга (оператор) язмача хәбәр җиткерүгә бурычлы.

6.8. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан дәүләт вазыйфасын үтәүгә контрольлек итү телефон аша мәгълүмат алу юлы белән, язмача мөрәҗәгать, электрон почта аша, Министрлык сайтында һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталлар аша хәл ителергә мөмкин.

6.9. Бу Регламентның үтәлешенә, шул исәптән гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан контрольлек итү тәртибенә һәм формаларына карата таләпләрне билгеләүче төп нигезләмәләр, федераль законнар, шулай ук Россия Федерациясенең башка норматив-хокукый актлары нигезендә билгеләнә.

## 7. Министрлык, шулай ук вазыйфаи затлары карарлары һәм гамәлләренә (гамәл кылмау) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

7.1. Юридик затлар (алга таба – мөрәҗәгать итүчеләр) Министрлык, аның вазыйфаи затларының дәүләт вазыйфасын үтәү барышында кабул иткән карарларына һәм кылган гамәлләренә (гамәл кылмау), буйсыну тәртибендә, югарыгы вазыйфаи затка судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерүгә хокуклы.

7.2. Мөрәҗәгать итүче почта аша яки "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып Министрлык сайты (http://www.minfin.tatar.ru/) аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы (http://uslugi.tatar.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru/) аша язмача, кәгазьдә яки электрон рәвештә шикаять белдерүгә, шулай ук Министрлыкка шәхсән шикаять тапшыруга хокуклы.

7.3. Судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү предметы булып Министрлыкның, вазыйфаи затларының дәүләт вазыйфасын үтәү барышындагы гамәлләре (гамәл кылмау) һәм кабул ителгән карарлары тора.

7.4. Министрлыкка яки вазыйфаи затка алынган шикаять, үз компентенциясе нигезендә, мәҗбүри төстә карап тикшерелергә тиеш. Судка кадәр (судтан тыш) шикаятьне карап тикшерүдән баш тартуга яисә карап тикшерүне туктатып торуга нигезләр күздә тотылмаган.

7.5.: Түбәндәге очракларда шикаятькә җавап бирелми:

– язмача шикаятьтә шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүченең фамилиясе (юридик зат атамасы) яки җавап җибәрелергә тиешле почта адресы (электрон адрес күрсәтелмәсә);

– шикаятьтә әдәпсез яки мыскыллау сүзләре, вазыйфаи затның, шулай ук аның гаиләсе әгъзаларының тормышына, сәламәтлеге һәм милкенә янаулар урын алса (Министрлыкның вазыйфаи заты шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә үз хокукыннан тиешенчә генә файдаланырга кирәклеге турында хәбәр җибәрүгә хокуклы);

– почеркы начар булу сәбәпле, шикаятьне укып булмаганда, бу хакта шикаятьне теркәгәннән соң җиде көн эчендә шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә – аның фамилиясен һәм почта адресын (электрон адрес) укып булганда;

– мөрәҗәгать итүче шикаятендә элегрәк җибәрелгән шикаятьләренә бәйле рәвештә инде берничә тапкыр язмача җавап бирелгән мәсьәлә күтәрелеп, шул ук вакытта шикаятьтә яңа дәлилләр як хәлләр китерелмәсә (әлеге шикаять Министрлыкка җибәрелгәндә, министр, вазыйфаи зат яки вәкаләтле зат чираттагы шикаятьнең нигезсезлеге һәм мөрәҗәгать итүче белән әлеге мәсьәлә буенча хат язышуны туктату турында карар кабул итүгә хокуклы. Шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә бу хакта хәбәр җиткерелә).

Шикаятьтә әзерләнелә, кылына торган як кылынган хокукка каршы гамәлләр турында, шулай ук аны әзерли, кыла торган яки кылган зат турында мәгълүматлар урын алган чакта шикаять тиешле компетенциядәге дәүләт органына җибәрелә.

Суд карарына шикаять белдерелгән шикаять теркәлгәннән соң җиде көн эчендә, әлеге суд карарына шикаять белдерү тәртибен аңлатып, мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарыла.

Шикаятьтә күтәрелгән мәсьәләнең асылына дәүләт сере яки федераль закон нигезендә сакланыла торган башка сер булган мәгълүматларны таратуга китермичә генә җавап биреп булмаган очракта шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә, әлеге мәгълүматларны таратуга ярамавы сәбәпле, күтәрелгән мәсьәләнең асылына җавап биреп булмау турында хәбәр ителә.

Шикаятьтә күтәрелгән мәсьәләләрнең асылына җавап биреп булмау сәбәпләре соңыннан юкка чыгарылган очракта мөрәҗәгать итүче Министрлыкка яки аның вазыйфаи затына янә шикаять җибәрүгә хокуклы.

7.6. Судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процедурасын башлауга нигез булып Министрлыкка дәүләт вазыйфасын үтәү барышында Министрлык, аның вазыйфаи заты гамәлләренә (гамәл кылмау) һәм кабул иткән карарларына шикаять белдерү тора.

7.7. Юридик затлар, башка кызыксынулы затлар шикаятьне нигезләү һәм карап тикшерү өчен кирәкле мәгълүмат һәм документлар алуга хокуклы. Мондый мәгълүмат һәм документлар алу өчен, юридик затлар башка кызыксынулы затлар Министрлыкка язмача яки электрон рәвештә запрос җибәрергә тиеш. Министрлыкның вазыйфаи затлары, Россия Федерациясе законында билгеләнгән мәгълүматка чикләүләр булмаган очракта, запросны теркәгәннән соң утыз көн эчендә юридик затка, башка

кызыксынулы затка соратыла торган мәгълүматлар һәм документлар тапшыруга бурычлы.

7.8. Министрлыкның вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмау) шикаять министрга җибәрелергә мөмкин. Министр гамәлләренә (гамәл кылмау) карарларына шикаять Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелергә мөмкин.

7.9. Шикаять Министрлык тарафыннан теркәлгәннән соң утыз көн эчендә карап тикшерелә.

7.10. Судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү нәтиҗәләре булып тора:

1) төбәк дәүләт күзәтчелеге хәл итү барышындагы гамәлләргә (гамәл кылмау) һәм кабул ителгән карарларга судка кадәр (судтан тыш) шикаятьне канәгатьләндерү, тәгаенләп әйткәндә:

а) хезмәт урынында тикшерү барышында вазыйфаи затның (вазыйфаи затлар) хезмәт бурычларын тиешенчә үтәмәве ачыкланган очракта вазыйфаи затка (вазыйфаи затлар) карата Россия Федерациясе законы нигезендә чаралар күрү;

б) хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре санга сугылмаган юридик затка Россия Федерациясе законын бозуларга гаепле вазыйфаи затларга карата күрелгән чаралар турында мондый чаралар күрелгәннән соң ун көн эчендә хәбәр җиткерә;

2) төбәк дәүләт күзәтчелеген хәл итү барышындагы гамәлләргә (гамәл кылмау) һәм кабул ителгән карарларга судка кадәр (судта тыш) шикаятьне канәгатьләндермичә калдыру (юридик затка мондый карарны нигезләп язмача хат җибәрү юлы белән).

Административ регламентка
№1 кушымта
(Типовой форма)

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының 30 апрель, 2009 ел,. № 141 боерыгы белән расланды

от 23 октября 2013 года №21-72-53 «Об утверждении Административного регламента исполнения Министерством финансов Республики Татарстан государственной функции по осуществлению регионального государственного надзора за проведением региональных лотерей, в том числе за целевым использованием выручки от проведения лотерей».

"___" ___________ 20___ ел

(актны төзү датасы)

______________________________
(актны төзү урыны)

______________________________
(актны төзү вакыты

**Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты тарафыннан юридик затны**

**ТИКШЕРҮ АКТЫ**

№ ___________

"___" ___________ 20___ ел. адресы: ______________________________
(тикшерү үткәрү урыны)

Түбәндәге нигездә:

______________________________

______________________________
(документ төре, реквизитларын (номеры, датасы,) тикшерүче дәүләт органы житәкчесенең, житәкче урынбасарының фамилиясен, исемен, атасының исемен (булганда), вазыйфасын күрсәтеп)

карата тикшерү
үткәрелде:______________________________
планлы/планнан тыш, документлар/күчмә

______________________________
(юридик зат атамасы)

Тикшерү үткәрү датасы һәм вакыты:
"___" _____ 20__ ел. __ час. __ мин. __ час. __ мин.кадәр. Дәвамлылыгы
______________________

Акт төзелде: ______________________________

______________________________
(тикшерүче дәүләт контрольлеге (күзәтчелек) органы атамасы)

Тикшерү үткәрү турында боерык күчермәсе белән таныштты: *(күчмә тикшерү үткәрелгәндә тутырыла)* ______________________________

______________________________

______________________________
(фамилияләре, исемнәре, атасының исемнәре (булганда), имза, дата, вакыты)

Тикшерү үткәрүне килештерү турында прокурор (аның урынбасары) карары датасы һәм номеры:

______________________________

______________________________
(тикшерүне прокуратура органнары белән килештерергә кирәк булганда тутырыла)

Тикшерүне үткәргән зат (затлар):

______________________________

______________________________
(тикшерүне үткәргән вазыйфаи затның (вазыйфаи затлар) фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы);

Тикшерү үткәргәндә катнашты:

______________________________

______________________________

_______________________________________________

(тикшерү чаралары үткәргәндә катнашкан юридик зат җитәкчесенең, башка вазыйфаи затының (вазыйфаи затлар) яки вәкаләтле вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы)

Тикшерү үткәрү барышында:

Мәҗбүри таләпләрне бозулар ачыкланды:_______________________________________

_______________________________________________

_______________________________________________

_______________________________________________

(бозулар рәвешен, бозуга юл куйган затларны күрсәтеп)

Лотерея шартларындагы мәгълүматларның мәҗбүри таләпләргә туры килмәве ачыкланды (норматив) хокукый актлар нигезләмәләрен күрсәтеп):_______________________

_______________________________________________

_______________________________________________

▪ ТР ФМ Казначылык департаменты күрсәтмәләрен үтәмәү фактлары ачыкланды (бирелгән күрсәтмәләрнең реквизитларын күрсәтеп)

_______________________________________________

_______________________________________________

▪ Бозулар ачыкланмады _______________________________________

_______________________________________________

Дәүләт контрольлеге органы тарафыннан юридик затны тикшерүләрнең Учет журналына язып куелды *(күчмә тикшерү үткәргәндә тутырыла)*:

_______________________ _______________________

(тикшерүче зат имзасы) (вәкаләтле юридик зат вәкиле имзасы)

Дәүләт контрольлеге (күзәтчелек) органы тарафыннан үткәрелә торган юридик затны тикшерүләрнең Учет журналы юк *(күчмә тикшерү үткәрелгәндә тутырыла)*:

_______________________ _______________________

(тикшерүче имзасы) (вәкаләтле юридик зат вәкиле имзасы)

Кушып бирелә торган документлар:_______________________________

Тикшерүне үткәргән затлар имзасы: _______________________________

_______________________________

Тикшерү акты белән танышты, барлык кушымталары белән, тикшерү акты күчермәсен алды:

_______________________

_______________________

(юридик зат җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), вазыйфасы)

"___" ____________ 20__ ел_____________

(имза)

Тикшерү акты белән танышудан баш тарту турында билге:_______________________

(тикшерүне үткәргән вәкаләтле вазыйфаи зат (затлар) имзасы))

Административ регламентка
№2 кушымта
(Типовой форма)

______________________________________________________________________________

(дәәәүләт контрольлеге (күзәтчелек) органы, атамасы, адресы, телефоны, факсы, e-mail)

______________________________________________________________

(контрольлек өлкәсендә)

**Тикшерүләр үткәрү нәтиҗәсендә ачыкланган бозуларны юкка чыгару турында**
**КҮРСӘТМӘ №**

"___" ____________ 20__ ел. ____________________ ш.

______________________________
Россия Федерациясе законы «__» _____ 20__ ел №___
таләпләрен үтәүне тикшерү актын нигезендә
мин,

______________________________________________________________________________
(вазыйфаи затның ФИО, вазыйфасы,
______________________________________________________________________________
хезмәт таныклыгы номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелүе)

КҮРСӘТМӘ БИРӘМ

______________________________________________________________________________
(үзенә күрсәтмә бирелгән юридик зат атамасы)

| № п/п | Күрсәтмә эчтәлеге <*> | Үтәү срогы | Күрсәтмә бирүгә нигез <**> |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | | | |
| | | | |
| | | | |

Күрсәтмәгә закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерелергә мөмкин. Шикаять белдерелү бу күрсәтмәне үтәүне туктатуга китерми.

Үзенә күрсәтмә бирелгән зат бу күрсәтмәне үтәү турында

______________________________________________________________________________ га
тикшерүче дәүләт контрольлеге (күзәтчелек) органы атамасы

аны үтәү срогы чыкканнан соң __ көннән дә соңга калмыйча мәгълүмат җибәрергә тиеш.

Вазыйфаи зат имзасы:

______________________________________ ______________ __________
(Ф.И.О.) (имза) (дата)

Күрсәтмәне алды

________________________________________ ________________________
( тикшерелә торган оешма житәкчесе (вәкаләтле вәкиле) Ф.И.О
(тикшерелә торган оешма житәкчесе (вәкаләтле вәкиле) имзасы)

--------------------------------

<*> Үзенә карата тикшерү үткәрелгән зат тарафыннан күрелергә тиешле конкрет чаралар күрсәтелә.

<**> Күрсәтмәдәге бурычны күздә тоткан норматив-хокукый актка сылтама күрсәтелә.

Административ регламентка
№3 кушымта
(Типовой форма)

**Административ хокук бозу турында**
**БЕРКЕТМӘ №**

"__" ________ 20__ ел ____________________
(төзү урыны)

Беркетмә төзелде ____________________________________________
(беркетмәне төзегән затның вазыйфасы, фамилиясе, атасының исеме)
____________________________________________

нигезендә ____________________________________________
(Россия Федерациясе/Татарстан Республикасы законы нормаларына сылтама)
карата: ____________________________________________
(үзенә карата эш кузгатылган юридик зат атамасы)
____________________________________________

Үзенә карата административ хокук бозу турында эш кузгатылган зат турында мәгълүматлар:
Юридик зат атамасы ____________________________________
Юридик адресы ____________________________________
Почта адресы ____________________________________
ОКПО, ОГРН коды ____________________________________
ИНН/КПП ____________________________________

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе Кодексының 25.1 статьясындагы 1 өлеше нигезендә, үзенә карата административ хокук бозу турында эш алып барыла торган зат барлык эш материаллары белән танышуга, аңлатмалар бирүгә, дәлилләр китерүгә, үтенечнамәләр һәм кире кагулар белдерүгә, яклаучысының юридик ярдәменнән файдалануга, шулай ук Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы нигезендә башка процессуаль хокукларга хокуклы.

Хокуклары һәм бурычлары аңлатылды:

__________ ______________ ______________________
(дата) (имзасы) (юридик затның законлы вәкиленең ФИО)

Административ хокук вакыйгасы һәм аның квалификациясе:
____________________________________________
(административ хокук бозу урыны, вакыты һәм вакыйгасы,
____________________________________________
санга сугылмаган Россия Федерациясе законы нормаларына сылтама, эш буенча дәлилләр күрсәтелә)
____________________________________________
____________________________________________
____________________________________________

Шул рәвешле, ____________________________________________
(юридик зат атамасы)
законда күздә тотылган административ хокук бозуга юл куйган ______________________
(санга сугылмаган Россия
____________________________________________
Федерациясе законына сылтама)

Үзенә карата административ хокук бозу турында эш кузгатылган зат аңлатмалары:
____________________________________________
____________________________________________
____________________________________________
____________________________________________

_____________ _________________ _____________________________________

(дата) (имзасы) (юридик затның законлы вәкиленең ФИО)

_____________________________________ ____________ _________________________

(беркетмәне төзегән зат вазыйфасы) (имзасы) (инициаллары һәм фамилиясе)

Беркетмә белән танышты:

__________ _________________ _____________________________________

(дата) (имзасы) (юридик затның законлы вәкиленең ФИО)

Беркетмә күчермәсен алды:

___________ ________________ _____________________________________

(дата) (имзасы) (юридик затның законлы вәкиленең ФИО)

Беркетмәне имзалаудан баш тарту очрагында имзалаудан баш тарту турында язып куела

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

Административ регламентка
№4 кушымта
(Типовой форма)

**Лотерея үткәрүгә рөхсәтнең гамәлдә булуын (кызыксындыру лотереясының гамәлдә булуын) туктатып тору турында**
**КАРАР**

"_____" __________ 20__ ел № ___

(карар кабул итү датасы)

Лотерея үткәрүгә рөхсәтне кире алу (кызыксындыру лотереясының гамәлдә булуын кире алу) турында судка гариза җибәрелү сәбәпле "____" _________ 20___ел № _____

_____________________________________________________________________________,
(лотереяның төре, атамасы, дәүләт теркәү номеры) оештырылган

_____________________________________________________________________________

_____________________________________________________________________________
(лотереяны оештыручының атамасы, юридик һәм почта адресы)

_____________________________________________________________________________,

_____________________________________________________________________________

һәм суд карары законлы көченә кергәнче лотерея үткәрүгә рөхсәтнең гамәлдә булуын (кызыксындыру лотереясының гамәлдә булуын) туктатып торырга "____" _________ 20____ ел № ______.

Нигезе: ____________________________________ "_____" ____________ 20___ ел.
(документ атамасы)

Министр (министрның беренче урынбасары )_______________ ___________________

(имзасы) (ФИО)

Административ регламентка
№5 кушымта
(Типовой форма)

**Лотерея үткәрүгә рөхсәтне кире алу турында (кызыксындыру лотереясының гамәлдә булуын туктатып тору турында) судка гариза җибәрү хакында**

**КАРАР**

"_____" __________ 20__ ел № ___

(карар кабул итү датасы)

Түбәндәгеләргә бәйле рәвештә
________________________________________________________________________________
(бозу төре)

________________________________________________________________________________

лотерея үткәрүгә рөхсәтне кире алу (кызыксындыру лотереясының гамәлдә булуын кире алу) турында судка гариза җибәрергә "____" _________ 20___ел № _____
________________________________________________________________________________
(лотерея төре, атамасы, дәүләт теркәү номеры)

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

оештырылган________________________________________________________________
(лотерея оештыручының атамасы, юридик һәм почта адресы)

________________________________________________________________________________

Нигезе: ______________________________________ "_____" ____________ 20___ ел

(документ атамасы)

Министр (министрның беренче урынбасары)_______________ ____________________________

(имза) (ФИО)

Административ регламентка
№6 кушымта
(Типовой форма)
Россия Федерациясе Икътисадый үсеш
министрлыгының 30 апрель, 2009 ел, № 141 боерыгы белән расланды

**Дәүләт контрольлеге (күзәтчелек) органы тарафыннан юридик затларны тикшерүләрнең учет**
**ЖУРНАЛЫ**

______________________________
(журналны башлау датасы)

______________________________
(юридик зат атамасы)

______________________________
(юридик зат (аларның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур подразделениеләре) адресы һәм аларның факттагы эшчәнлек урыны (урыннары)

______________________________
(юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында язуның дәүләт теркәү номеры)

Җаваплы зат: ______________________________

______________________________
(тикшерүләрнең учет журналын алып баруга җаваплы затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы)

______________________________
(юридик зат җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Имзасы: ______________________________
М.У.

Үткәрелгән тикшерүләр турында мәгълүматлар

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Тикшерүне башлау һәм тәгәлләү датасы | |
| 2 | Тикшерү үткәрүнең гомуми вакыты | |
| 3 | Дәүләт контрольлеге (күзәтчелек) органы атамасы | |
| 4 | Тикшерү үткәрү турында боерык датасы һәм номеры | |
| 5 | Тикшерү максаты, бурычлары һәм предметы | |
| 6 | Тикшерү төре (планлы һәм планнан тыш)<br>планлы тикшерүгә карата:<br>- тикшерүләр үткәрүнең еллык планына сылтама белән;<br>планнан тыш күчмә тикшерүгә карата:<br>- тикшерү үткәрүне килештерү турында прокурор карары датасын һәм номерын күрсәтеп (мондый килештерү кирәк булганда) | |
| 7 | Тикшерү нәтиҗәләре буенча төзелгән акт датасы һәм номеры, аны юридик зат вәкиленә тапшыру датасы | |
| 8 | Ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозулар (ачыкланган бозуның эчтәлеге күрсәтелә, таләпне бозуга юл куйган затны күрсәтеп, санга сугылмаган норматив-хокукый акт нигезләмәсенә сылтама) | |
| 9 | Ачыкланган бозуларны юкка чыгару турында бирелгән күрсәтмәнең датасы, номеры һәм эчтәлеге | |
| 10 | Тикшерүне үткәргән вазыйфаи затның (вазыйфаи затлар) фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы | |
| 11 | Тикшерү үткәрүгә җәлеп ителгән экспертларның, эксперт оешмалары вәкилләренең фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре, вазыйфалары | |
| 12 | Тикшерү үткәргән вазыйфаи затның (затларның) имзасы | |

Административ регламентка
№7 кушымта
(Типовой форма)
Россия Федерациясе Икътисадый үсеш
министрлыгының 30 апрель, 2009 ел,. № 141 боерыгы белән расланды

______________________________________________________________
(дәүләт контрольлеге (күзәтчелек) органы атамасы)

**БОЕРЫК**

тикшерү ______________________________________________ үткәрү турында
(планлы/планнан тыш, документар/күчмә)

юридик затка
"___" ________________ ел № ______

1. түбәндәгегә карата тикшерү үткәрергә
_______________________________________________________
______________________________________________________________
(юридик зат атамасы)

2. Урнашу урыны:
______________________________________________________________
______________________________________________________________
______________________________________________________________
(юридик затның (аларның филиалларының, вәкиллекләренең, аерымланган структур подразделениеләренең) урнашу урыны һәм аларның факттагы эшчәнлек урыны (урыннары)

3. Тикшерү үткәрүгә вәкаләтле зат (затлар) итеп билгеләргә: ____________________
______________________________________________________________
______________________________________________________________
(тикшерү үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затның (вазыйфаи затлар) фамилиясе, исеме, атасының исеме(булганда), вазыйфасы)

4. Түбәндәге затларны экспертлар, экспертлар вәкилләре сыйфатында тикшерү үткәрүгә җәлеп итәргә:
______________________________________________________________
______________________________________________________________
______________________________________________________________
(тикшерү үткәрүгә җәлеп ителгән экспертларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре (булганда), вазыйфалары һәм (яки) эксперт оешмасы атамасы, аккредитация турында таныклык реквизитларын һәм аккредитация турында таныклык биргән аккредитация органы атамасын күрсәтеп)

5. Бу тикшерүнең түбәндәге максатта үткәрелүен билгеләргә:
______________________________________________________________
______________________________________________________________

бу тикшерүнең бурычлары булып тора:
______________________________________________________________
______________________________________________________________
______________________________________________________________

6. Бу тикшерүнең предметы булып тора:
лотерея шартларындагы мәгълүматларның туры килүе;
күрсәтмәләрнең үтәлүе;
ТР ФМ Казначылык департаментына кулланучыларның санга сугылмаган хокуклары турында гражданнардан, юридик затлардан мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, дәүләт хакимияте

органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан мәгълүматлар алынуга бәйле чаралар үткәрү.

7. Тикшерүне үткәрү срогы: ______________________________________________

Тикшерү үткәрүгә керешергә
"___" ____________ 20___ ел
Тикшерүне түбәндәге датадан соңга калмыйча төгәлләргә:
"___"____________ 20___ ел

8. Тикшерүне үткәрүгә хокукый нигезләр: ________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
(тикшерү үткәрүгә нигез итеп алынган норматив-хокукый акт нигезләмәсенә сылтама; тикшерү предметы булып торган таләпләрне билгеләүче (норматив) хокукый актлар нигезләмәләренә сылтама)

9. Тикшерү процессында тикшерү үткәрү максатларына һәм бурычларына ирешү өчен кирәкле түбәндәге контрольлек чараларын үткәрергә: _______________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

8. Тикшерү үткәрү өчен кирәкле контрольлек чаралары үткәрүнең административ регламентлары (булганда)исемлеге: ___________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
(аларның атамаларын, эчтәлеген, төзү даталарын һәм төзегән затларны күрсәтеп)

10. Тикшерү үткәрелгәндә юридик зат тарафыннан тапшырылырга тиешле документлар исемлеге:
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

______________________________________
______________________________________
(ТР финанс министрының беренче урынбасары – ТР ФМ Казначылык департаменты директоры вазыйфасы, фамилиясе, инициаллары)

______________________________
(мөхер белән расланган имза)

______________________________________________________________________
(проектны (боерык) турыдан-туры әзерләгән вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда) һәм вазыйфасы, элемтәгә керү өчен телефоны, электрон адресы (булганда)

Административ регламентка
№8 кушымта
(Типовой форма)
Россия Федерациясе Икътисадый үсеш
министрлыгының 30 апрель, 2009 ел, № 141 боерыгы белән расланды

____________________________________________га
(прокуратура органы атамасы)
____________________________________________дан
(дәүләт контрольлеге (күзәтчелек) органы атамасын күрсәтеп)

**Дәүләт контрольлеге (күзәтчелек) органынының юридик затка планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне прокуратура органы белән килештерү турында**
**ГАРИЗА**

1. “Дәүләт контрольлеген (күзәтчелек) һәм муниципаль контрольлекне хәл иткәндә юридик затларның һәм хосусый эшмәкәрләрнең хокукларын саклау турында” 26 декабрь, 2008 ел, N 294-ФЗ " Федераль законның (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2008, N 52, 6249 ст.) 10 статьясы нигезендә, түбәндәгегә карата планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүгә ризалык бирүегезне сорыйбыз ____________________________________________________________

______________________________________________________________________________
(даими эшләүче юридик затның башкарма органы атамасы, адресы (урнашу урыны), юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында язуның дәүләт теркәү номеры/хосусый эшмәкәрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), яшәү урыны, хосусый эшмәкәрне дәүләт теркәвенә алу турында язуның дәүләт теркәү номеры, салым түләүченең идентификация номеры)

Түбәндәге адрес буенча эшчәнлек алып бара:_____________________________

______________________________________________________________________________

2. Тикшерү үткәрүгә нигез:

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________
(“Дәүләт контрольлеген (күзәтчелек) һәм муниципаль контрольлекне хәл иткәндә юридик затларның һәм хосусый эшмәкәрләрнең хокукларын саклау турында” 26 декабрь, 2008 ел, N 294-ФЗ " Федераль закон нигезләмәсенә сылтама)

3. Тикшерү үткәрүгә керешү датасы:
"__" _____________ 20__ ел

4. Тикшерү үткәрүгә керешү вакыты:
"____" ______________ 20__ ел
(тикшерү үткәрүгә нигез булып “Дәүләт контрольлеген (күзәтчелек) һәм муниципаль контрольлекне хәл иткәндә юридик затларның һәм хосусый эшмәкәрләрнең хокукларын саклау турында” 26 декабрь, 2008 ел, N 294-ФЗ Федераль законның 10 статьясындагы 12 өлеше торганда күрсәтелә )

Кушып бирелә:
______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________
(планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында дәүләт контрольлеге (күзәтчелек) органы житәкчесенең, житәкче урынбасарының боерыгы күчермәсе. Планнан тыш тикшерү үткәрүгә нигез булып хезмәт иткән мәгълүматлардан торучы документлар )


________________________________ ____________ ________________________________
(вазыйфаи зат атамасы) (имзасы) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)

М.У.

Документны тутыру датасы һәм вакыты: ________________________________

Административ регламентка
№9 кушымта

## Дәүләт вазыйфасын үтәүнең блок-схемасы



Күчмә тикшерү үткәрелә:
1) юридик зат тарафыннан тапшырылган аңлатмаларны һәм документларны карап тикшергәннән соң Министрлык мәҗбүри таләпләне бозу билгеләрен ачыкласа:
Аңлатмалар бирелмәсә:
3) документар тикшерү вакытында мөмкин булмаса.
- юридик зат тапшырган мәгълүматларның тулылыгын һәм дөреслеген дәлилләп булмаса:
- күчмә тикшерү үткәрмичә генә юридик зат эшчәнлегенең мәҗбүри таләпләргә туры килүен бәяләп булмасар
3) если при документарной проверке не представляется возможным:
- удостовериться в полноте и достоверности сведений, представленных юридическим лицом;
- оценить соответствие деятельности юридического лица обязательным требованиям без проведения выездной проверки

Бозулар күрсәтмәдә күрсәтелгән сроктан соң гына юкка чыгарылды. РФ КоАП нигезендә беркетмә төзелә

Бозулар юкка чыгарылмады, РФ КоАП нигезендә административ хокук бозу турында беркетмәләр төзү

Регламентның 2.4.2.п."а" нигезе буенчапланнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында боерык